• ӘҢГӘМӘ •

БӘРӘКӘТЛЕ УРАЗА (ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ)

*4 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •

НАМАЗ УКЫМАСАМ, УРАЗА ТОТА АЛАММЫ?

*7 бит*

• ТАРИХ •

ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ НӘСЕЛЕ КАЗАНДА ЯШӘГӘН?

*11 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •

ОЛЫ ГӨНАҺЛАР

*13 бит*

*№ 4 (297)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *Рамазан 1441*

*Апрель, 2020*

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Рамазан аеның без белмәгән серләре бар...




Рамазан уразасын бик күпләребез тотабыздыр. Әмма аның ни өчен шәригатебездә шундый урын тотканын һәркем дә әйтеп бирә алмас. Рамазан – бер ай гына түгел, ул үзе бер дөнья.

*Дәвамы 9 нчы биттә*

12+

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

# Игътибар! Намаз вакытларында үзгәрешләр бар



**Хөрмәтле дин кардәшләребез!**

Ел саен, май аеннан башлап (Казан өчен 5 нче майдан) август башына кадәр, безнең төбәкнең географик үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, кояш баткандагы шәфәкъ яктылыгы иртәнге шәфәкъ аклыгы белән кушыла, ягъни төн дәвамында офыкта яктылык югалмый. Шуңа бәйле рәвештә, астрономик исәпләүләр ярдәмендә, ястү намазы башлануның төгәл вакытын, шулай ук сәхәр тәмамлануны һәм иртәнге намаз вакыты керүне төгәл итеп билгеләп булмый башлый. Быел әлеге вакыт Рамазан аена туры килүенә игътибарыгызны юнәлтәбез.

**Нәкъ менә шуңа күрә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмаләр шурасы намаз вакыты керә торган якындагы төбәккә карап, намаз вакытларын исәпләү юлы белән билгеләргә карар кылды. Бу карар Голәмәләр шурасы тарафыннан ТР календарьләре өчен намаз вакытын билгеләү системасына һәм аны исәпләп чыгаруга кертелде.**

Без илебезнең атаклы галиме, имам Шиһабетдин Мәрҗани фикеренә таяндык, ул без яшәгән төбәктә югарыда телгә алынган айлар өчен ястү һәм иртәнге намаз вакытларын исәпләгәндә әлеге намаз вакытлары чын-чынлап керә торган җирлеккә карап исәпләү кирәклеге турында әйткән. Мәсәлән, Әстерхан шәһәре 46 нчы географик киңлектә һәм, Татарстанныкы кебек үк, географик озынлыкта урнашкан.

4 май көнне Казанда иртәнге намаз 00:06 сәгатьтә керә, ә 5 нче май көнне чын төн юк. Санау юлы белән исәпли башлау элекке көн вакыты белән чагыштырганда шактый аерма китереп чыгара. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, иртәнге намазның башлану вакыты – ураза башлану вакыты булып тора.

**Игътибарлы булыгыз һәм намаз вакытларын күзәтеп барыгыз!**

■ **dumrt.ru**

# «Сәламәт Рамазан» онлайн-марафон




Уразаның беренче көнендә «Сәламәт Рамазан» Бөтенрәсәй онлайн-марафоны башланачак. Марафонда катнашып, сез файдалы гадәтләр генә үзләштереп калмыйча, күпсанлы бүләкләр оту мөмкинлегенә дә ия булачаксыз.

Марафонны оештыручы – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты – Коръән мәгънәләренең рус һәм татар телләрендә уникаль тәрҗемәләрен һәм аларның дискларга яздырылган аудиоверсияләрен, рамкалы зур бер плакатка язылган Коръән, шулай ук китаплар сатып алу өчен карта бүләк итәчәк.

Проектның генераль партнеры – «АК БАРС-Мед» иминият компаниясе» ЖЧҖ – җиңүчеләргә check-up (профиль – ирекле) медицина тикшерүенә сертификатлар, «Мобильный доктор» ирекле медицина иминияте полислары һәм спорт җыелмалары бирәчәк.

«Сәламәт Рамазан» онлайн-марафоны ике мәйданчыкта – Инстаграмда Islam-Today.ru порталының рәсми төркемендә һәм «ВКонтакте» төркемендә узачак.

Көн саен аккаунтларда биремнәр белән язмалар дөнья күрәчәк, һәр 10 көн саен саннарны әйләндерү ярдәмендә язма астында бүләкләр уйнатылачак. Катнашучылар беренче биремне 24 апрель көнне 20:00 сәгатьтә күрә алдылар.

«Сәламәт Рамазан» онлайн-марафонында катнашу шартлары һәм тәртипләре белән Инстаграм социаль челтәрендә @islam_today_huzur аккаунтында танышырга мөмкин.

■ **dumrt.ru**

# Рамазан – изге гамәлләр ае

**Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны башланды: авыру балалар, аз керемле гаиләләр һәм мохтаҗлар ярдәм көтә**

**Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны башланды. Ел саен уздырыла торган акция Рамазан ае кысаларында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан авыру балаларга, аз керемле гаиләләргә һәм мохтаҗларга ярдәм итү йөзеннән игълан ителде. Традицион рәвештә нәкъ менә шушы изге айда республикабыз мөселманнары хәйриячелек өлкәсендә иң зур активлык күрсәтә, чөнки Рамазан аенда садака бирү бик күркәм гамәлләрдән санала. Изге гамәлләр кылу, аз керемлеләргә һәм авыруларга карата юмартлык күрсәткән өчен саваплар шушы 30 көндә күпкә тапкырлана һәм ул адәм баласын Аллаһы Тәгаләгә тагын да якынайта.**

## Балаларга ярдәм

Ярдәмгә мохтаҗ беренче авыру бала – Дәлил Вәлиев. Аңа 3 яшь. Бала гипертензия-гидроцефаль синдромы һәм кан тамырлары шеше белән дөньяга килгән. Өч айдан Дәлил күзләрен йома башлый. Бер яшьтә тугыз айда аңа соңгы диагноз куялар: «үз-үзеңне тотышның аутистик тайпылышы белән психо-сөйләм үсешен тоткарлау формасындагы резидуаль энцефалопатия». Әгәр малай югары сыйфатлы дәвалану алса, бу «җыелма» диагноз бетәргә мөмкин. Дәлилнең әнисе һәм әтисе баланы дәвалау өчен бөтен мөмкинлекләрне куллана, әмма курслар түләүле һәм алар бик күп. Билгеле ки, гаиләдә хәзер берданбер туендыручы – ул сабыйның әтисе, әмма Вәлиевлар кардәшләребезнең ярдәменә өметен югалтмый. Кирәкле сумма – 60000 сум.

Ярдәмгә мохтаҗ икенче баланың исеме Константин Баранов. Аңа 4 яшь. Аның әнисе баланы вакытыннан алда тапкан, һәм бу, әлбәттә, сабыйның сәламәтлегендә чагылыш тапкан. Хәзер Константинда авыр формадагы ДЦП… Малайның әти-әнисе улының хәлен яхшырту өчен кулдан килгәннең барысын да эшли. Әмма бу җиңел түгел, чөнки гаиләдә әти кеше генә эшли, ә әни тәүлек буена түләнми торган эштә – ул авыру баланы карый. Балага өзлексез рәвештә дәвалану таләп ителә. Кирәк булган сумма – 60’000 сум. Кызганыч ки, Костяның әти-әнисенең дәвалауны мөстәкыйль рәвештә түләргә мөмкинлеге юк. Алар ярдәм сорыйлар.

Ярдәмгә мохтаҗ өченче бала – Камилла Киреева. Бу шат күңелле кызга 21 яшь. Диагнозларның тулы бер «бәйләме»нә дә карамастан, аның йөзеннән елмаю китми: ДЦП, спастик тетрапарез, 3-4 нче дәрәҗәдәге умыртка сөяге кәкрәю, күрү нервларының өлешчә атрофиясе… Камилла бу авырулар белән батырларча көрәшә, һәм бу эштә аңа кызын үзе генә тәрбияләгән яраткан әнисе булыша. Мәрхәмәтле кешеләр аларга тернәкләнү курслары узарга ярдәм итә, чөнки Фәридә ханым авыру кызын даими рәвештә карау аркасында эшли алмый. Чираттагы курс 60000 сум тора.

Ярдәмгә мохтаҗ дүртенче бала – Руфат Агаевка – 13 яшь, һәм ул елан чаккан аркасында инвалид булып калган. Елан чаккач ул аңын югалта. Берникадәр вакыттан соң Руфат аңына килә, шуннан соң анда физик тайпылышлар гына түгел, психик тайпылышлар да башлана. Гаиләдә, Руфаттан тыш, тагын биш бала тәрбияләнә, һәм биредә бары тик әти кеше генә эшли, аңа әле шулай ук үзенең авыру әнисе турында да кайгыртырга кирәк. Руфат өчен чираттагы тернәкләнү курсы 60’000 сум тора, бу акча аның әти-әнисендә, әлбәттә, юк. Ул сезнең ярдәмгә мохтаҗ.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Иң яхшы садака – Рамазан ае садакасы». Аллаһы Тәгалә изге гамәлләрегезне кабул кылсын!**

**Әлеге авыру балаларга ярдәм итүнең берничә юлы бар:**

**Беренчесе:** 7715 номерына САДАКА сүзен язып SMS-хәбәр җибәрергә. Хәбәрнең бәясе 50 сум.

**Икенчесе:** SMS-хәбәрдә САДАКА сүзен язарга, буш ара калдырырга һәм кирәкле сумманы язарга. Мисал өчен, САДАКА 300. Бу очракта кәрәзле телефон хисабыннан 300 сум күчереләчәк.

**Өченчесе:** 5336 6900 3516 7669 номерлы Саклык банкы картасы («Зәкят» фонды хезмәткәре Әлмәтов Илнур Мәхмүт улы).

## Аз керемле гаиләләргә ярдәм

Моннан тыш, Рамазан аенда ТР мөселманнары Диния нәзарәте традицион рәвештә аз керемле гаиләләргә һәм мохтаҗларга азык-төлек ярдәме күрсәтә.

Исегезгә төшерәбез, узган ел, мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Казанның 900 аз керемле гаиләсенә 5,5 тоннадан артык азык-төлек тапшырды.

Дөньяда, илдә һәм республикабызда килеп туган вәзгыятькә карамастан, без бу социаль бурычны быел да бергә башкарып чыга алырбыз дип өметләнәбез. Өстәвенә, Татарстан территориясендә гомуми рәвештә үз-үзеңне читләштерү режимы кертелү сәбәпле, өлкән һәм ялгыз кешеләр өйдә генә тора һәм аларның азык-төлек алырга чыгу мөмкинлеге юк. Үз-үзеңне читләштерү режимы кертелгәннән алып, ТР мөселманнары Диния нәзарәтеннән азык-төлек җыелмаларын йөздән артык кеше алды. Шул рәвешле, ярдәм күрсәтү дәвам итә. Азык-төлек җыелмасына он, төрле ярмалар, көнбагыш мае, консервалар, шикәр, макарон, чәй, как һәм кәнфитләр керә.

Ярдәм күрсәтү өчен «Зәкят» хәйри фондына шалтыратырга була.

## VIII Республикакүләм ифтар

Дөньяда, илдә һәм республикадагы санитар-эпидемиологик вәзгыятькә карамастан, Татарстанда VIII Республикакүләм ифтар уза. Ифтарны оештыручылар – ТР мөселманнары Диния нәзарәте, «Ак Барс Арена» стадионы һәм «Туган авылым» милли-туристик комплексы – пандемияне һәм шулай ук Татарстанда игълан ителгән ТАССРның йөзьеллыгын исәпкә алып, проект форматын үзгәртү карарын кабул итте.

ТАССРның 100 еллыгына багышланган VIII Республикакүләм ифтар "100-еллык ифтары" исеме астында уза һәм җөмһүриятебез буенча 30 000 кешене колачлый. Нәтиҗәдә, узган елгы ифтар белән чагыштырганда, аның катнашучылар саны ике тапкырга артты. Исегезгә төшерәбез, узган елны авыз ачуда берьюлы 15 000 кеше катнашкан иде.

**Пандемия шартларында иминлекне тәэмин итү максатыннан, VIII Республикакүләм ифтар ризыкларны өйгә китереп бирү рәвешендә тормышка ашырылачак һәм халыкның бары тик мохтаҗ катлауларын гына күздә тота. Моннан тыш, «100 еллык ифтары» узган еллардагы кебек бер генә көн түгел, ә Рамазан ае дәвамында узачак.**

■ **dum.rt**

# Бәрәкәтле ураза

**Рамазан аенда иң олуг гыйбадәт – ураза. Без аны зарыгып көтеп алабыз, бик авырдан гына озатып калабыз. Әмма бу айны ничек итеп җиңел һәм бәрәкәтле итеп үткәрергә соң? Организмыбызга зыян салмас өчен нишләргә? Бу хакта табиб белән киңәшләшергә булдык. Бездә кунакта Казан шәһәренең 7 нче клиник хастаханәсенең нейрохирургы – Раушан Хәсәнов.**



– Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ, хөрмәтле дин кардәшләрем.

**– Вә галәйкүм әссәләм. Әйтегез әле, ураза тотар алдыннан организмны ничек әзерләргә?**

– Шәгъбан аенда безнең сөннәт уразаларыбыз була, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе уразалары бар, шулай ук Бәраәт кичәсендә нәфел уразасы бар. Аларны тоту безнең организмыбызны күнектерү булып санала инде. Шулай ук, көненә бер тапкыр гына ашау гадәтен калдыру, мәсәлән, төшке ашны калдырып, баллы, тозлы әйберләрдән тыелу тәнебезне чыныктыру булыр иде.

**– Рамазан аенда тәнебезне сусызлыктан һәм кибүдән ничек сакларга?**

– Рамазан аенда һәм башка айларда да безнең организмыбызга литр ярым, ике литр су, сыеклык кирәргә тиеш. Шуның өчен без сәхәрне, ифтарны (авыз ачуны) бер тәртипкә салып, су эчү гадәтен җайга салырга тиеш. Ярты литр су яки сыеклык – иртәнге якта сәхәрдә булса, калган өлешен без инде ифтарда тулыландырабыз.

**– Рамазан аенда нәрсә эчәргә киңәш ителәә?**

– Рамазан аенда су, күбрәк җиләк-җимеш сулары эчү тәкъдим ителә, чөнки безнең су һәм электролит балансыбызны тулыландыру өчен; әмма чәйгә килгәндә, чәйне эчү сәхәр вакытында тәкъдим ителми, чөнки чәй (белән) безнең организмнан су чыгу көчәя, шуның өчен без электролитларны югалтабыз. Шуның өчен чәйне күбрәк ифтар вакытында эчәргә кирәк. Сәхәр вакытында күбрәк су һәм җиләк-җимеш сулары эчү дөрес булыр.

**– Авыз ачканнан соң суны зур күләмдә эчү ризык кабул итүгә зыян итмиме?**

– Артыклык, башка әйберләрдә кебек үк, суны артык эчү көне буе (буш торган) организмыбызга авырлык китерү була. Шуның өчен берәр стакан күләмендә су эчеп, авызыбызны ачсак, аннары ахшам намазын укып, үзебезнең төп ашавыбызга керешү дөрес булыр.

> *«Туклыклы ризыклар: диетик яктан дөрес саналган ит; аксымга бай ризыклар, ягъни эремчек, йомырка; клетчаткага бай ризыклар, ягъни боткалар».*

**– Су балансын нормага кайтарыр өчен ничек авыз ачарга?**

– Авызыбызны бер стакан су белән һәм өч хөрмә җимеше белән ачсак дөрес булыр, ә аннары ахшам намазын укып, бер ярты сәгатьтән соң, төп ашауга керешеп, шул ашау вакытында әкрен генә даими рәвештә су, җиләк-җимеш сулары эчәргә кирәк. Шулай итеп, үзебезнең организмыбызны электролитлар белән тулыландырган булырбыз.

**– Барлык җиләк-җимешне дә ач килеш ашарга ярыймы?**

– Барлык җиләк-җимешне дә ач килеш ашау дөрес булмас. Организмыбызда көне буе ашау (ризык) тулыланмагач, безнең организмыбызга цитруслылар: әфлисун, лимон шикелле җиләк-җимешләр һәм дә виноград зыян китерергә мөмкин. Шуның өчен аларны төп ашаудан соң кабул итү дөрес булыр. Инде көне буе организмыбыз ашау кабул итмәгәч, безнең ашказанында әчелекне (кислотность) арттырмас өчен, цитруслылар рәтеннән: әфлисун яки лимон шикелле җиләк-җимешне кабул итү зыян китерергә мөмкин. Ә виноград ашау эчебезнең кабаруына яки газлар барлыкка килүгә китерергә мөмкин.

**– Авыз ачканнан соң нишләргә киңәш ителәә?**

– Ифтардан соң, кеше бераз хәл алганнан соң, кешенең тәравих намазларына басуы дөрес булыр, чөнки хәрәкәтләнү үзебезнең организмыбызга килгән ризыкларны кабул итәргә ярдәм итәчәк. Ифтардан соң кемнеңдер спорт белән яки авыр хезмәт белән шөгыльләнәсе килсә, берәр сәгатьтән соң гына керешүе дөрес. Ә урамда йөреп, бераз хәрәкәтләнеп керү зыян булмас.

**– Сәхәргә нәрсә ашарга киңәш ителәә?**

– Сәхәргә аксымнар күбрәк булган ризыклар кабул итү һәм дә клетчаткага бай боткалар белән организмыбызны тулыландыру дөрес булыр, чөнки клетчатка әкрен углевод булып санала. Әкрен углеводлар кабул иткәндә, көне буена даими рәвештә безнең канга углеводлар кереп барчак. Шуның өчен клетчаткага һәм дә аксымга бай (чикләвек, күрәгә һәм дә җиләк-җимеш кебек) ризыклар ашау дөрес булыр.

**– Авыз ачканда һәм сәхәрдә ничек итеп артыгын ашамаска?**

– Ашаганда, сөннәтебез буенча, ашказанын өч өлешкә бүлеп карау тиешле. Бер өлеше ризык булса, икенче өлеше – су, ә өченче өлеше – һава. Шуның өчен ашаганда әкренләп, ашыкмыйча гына ашап, үзебезнең тукланыуыбызны сизеп, ашаудан туктау дөрес булыр. Шул ук вакытта суны тулыландыруны да онытмаска кирәк.

**– Кайсы ризыклар туклыклырак булып санала?**

– Туклыклы ризыкка безнең аксым күп булган һәм клетчаткага бай булган углеводлар керә. Туклыклы булып, май составы күп булмаган, диетик яктан дөрес булган ит, аксым күп булган ризык – эремчек, йомырка, ә клетчаткага бай булган ризыклар – күп төрле боткалар керә. Аларны ашау туклыклы матдәләрне кабул итү була.

**– Рамазан аенда кайсы ризыкларны ашауны тыярга кирәк?**

– Кыздырылган, майлы, әче һәм тозлы булган ризыкларны чикләү дөрес булыр. Чәй белән каһвәгә килгәндә, сәхәр вакытында аларны чикләргә кирәк, чөнки алар безнең (организмыбыздан) су чыгаруны арттыралар. Су чыкканда без үзебезнең минералларыбызны югалтабыз. Шуның өчен тыелып тору дөрес булыр.

■ **Әңгәмәне «Хозур ТВ» үткәрде**

# Муса галәйһиссәлам кыйссасы

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

### Сихерчеләрнең дине һәм аларның һәлак булуы

Муса галәйһиссәламнең могҗизасын күргәч сихерчеләр башларын җиргә орып, болай дип әйтәләр:

**«Без Һарун белән Мусаның Раббысына иман китердек».**

«Та һа», 20:70

Ә фиргавеннең моңа бик ачуы чыга һәм:

**«(Димәк) Мин сезгә рөхсәт бирүдән алда сез аңа иман китердегез! Һичшиксез, ул (Муса) – сезгә бу сихерне өйрәткән сезнең башлыгыгыз. (Сез бу эшне үзара аңлашып, аннан кечерәк сихерләр ясадыгыз, ул исә, сездән өстенлеген күрсәтеп, сезне җиңде) Мин сезнең кулларыгызны һәм аякларыгызны (уң кул, сул аяк шәкелендә) чалыштырып чабып өзәчәкмен, шуннан соң сезне хөрмә кәүсәсенә кагып куячакмын. Менә шулвакыт кайсыбызның (минемме, Мусаның илаһыныңмы) көчлерәк һәм дәвамлырак икәнен белерсез».**

«Та һа», 20:71

Ләкин иман китергән сихерчеләр бу янауларга һич тә игътибар итмиләр һәм фиргавенгә болай дип әйтәләр:

**«Әйттеләр: «Безгә килгән ачык могҗизаларга һәм безне юктан бар кылган Ул Затка каршы сине сайламаячакбыз. Син карар биргән нәрсәңә хөкем ит. Син дөнья тормышында гына хөкем итәсең. (Синең көчең бу фани дөньяда гына бар, бик тиздән ул юкка чыгачак) Һичшиксез, без хаталарыбызны һәм синең безне көчләп кылдырган сихерчелегең өчен безне гафу итсен дип, Раббыбызга иман китердек. Аллаһы яхшырак, (савап ягыннан да, газап ягыннан да) дәвамлырак».**


«Та һа», 20:72-73

Кан коюдан беркайчан да чирканмаган фиргавен, сихерчеләрнең кулаякларын чабып өзәргә һәм аларны тәрегә кадакларга боера. Бу сихерчеләрнең исламдагы хәле, чыннан да, гаҗәеп. Әле иртән генә алар имансыз иделәр, ә кичкә инде исламның шәһитләре булалар. Бер көннән азрак кына мөэмин булып яшәсәләр дә, алар иманда камиллеккә ирешеп, үз тормышларын дин юлында корбан итәләр.

Муса галәйһиссәлам халкы фиргавеннең сихерчеләр белән ни кылганын, аларның кул-аякларын чабып өзеп, тәрегә кадаклап үтерергә боерганын күргәч, ул безнең белән дә шуны эшләргә мөмкин бит дип куркуга кала. Муса галәйһиссәлам аларга:

**«Аллаһыдан ярдәм сорагыз һәм (дошманнарыгызның җәфалавына һәм үзегез хакында ишеткән нигезсез сүзләргә карата) сабыр булыгыз. Һичшиксез, (бөтен) җир (йөзе) Аллаһыныкы гына. Ул колларыннан теләгәннәрен аңа варис итәр. (Хәерле) Ахыр исә тәкъва ияләренә (булачак, шуңа күрә фиргавеннең уйдырып сөйләгәннәренә ышанмагыз, ул әйткәнчә булмас, Аллаһы боерганча булыр)».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:128



### Фиргавен һәм аның халкына галәмәт итеп җибәрелгән афәтләр

Иманга килсеннәр өчен Аллаһы Тәгалә фиргавен һәм аның халкына бер-бер артлы төрле афәтләр җибәрә. Башта сигез көн буе бертуктамый яңгыр коя. Беркем дә өеннән чыга алмый. Су шулкадәр күтәрелә ки, хәтта кешеләр өйләрендә муеннан суга батып йөрергә мәҗбүр булалар. Ләкин исраиллеләрнең өйләренә су кагылмый. Шулай итеп җиде көн буе Мисыр диңгез кебек була.

Тулысынча суга батудан куркып, фиргавен халкы Муса галәйһиссәламгә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Алар:

– Раббыңа дога кыл безне бу афәттән коткарсын, шунда без иман китерербез, – дип әйтәләр.

Муса галәйһиссәлам дога кыла һәм бу афәт бетерелә. Тик бу вакыйгадан соң үсемлекләр шаулап үсә башлый. Моңа кадәр андый бәрәкәтне күрмәгән халык иманга килүдән баш тарта:

– Без курыккан афәт куркыныч булмаган икән, киресенчә, бәрәкәт китерде, – диләр.

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларга саранча өере җибәрә. Саранчалар өере бөтен уңышны ашап бетерә яза, кешеләрнең өйләренә кереп тула. Мондый казага тарыган Фиргавен халкы, шул ук сүзләр белән, Муса галәйһиссәламгә тагын мөрәҗәгать итә:

– Раббыңа дога укы, безне бу афәттән коткарсын, шунда без иман китерербез, – дип әйтәләр.

Муса галәйһиссәлам дога кылгач, Аллаһы Тәгалә җибәргән җил бөтен саранчаны диңгезгә алып китә. Калган уңышның аларга яшәргә җиткәнен күргәч, фиргавен халкы:

– Уңышның калганы безгә җитәчәк, – дип иман китерүдән тагын баш тарта.

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларга бет һәм башка бөҗәкләр җибәрә. Бу бөҗәкләр уңышның саранчалардан калган өлешен ашап бетерә башлый-лар, бетләр кешеләрне тешләп каннарын эчәләр. Шунда кешеләр өченче тапкыр Муса галәйһиссәламгә киләләр һәм аларны бу бәладән коткаруын сорап, иман китерергә вәгъдә итәләр. Аллаһы Тәгалә аларны бу бәла-казалардан да азат итә. Ләкин бу кешеләрне тагын иманга китерми:

– Хәзер инде синең сихерче булуыңда безнең бернинди дә шигебез калмады, – дип әйтәләр.

Болардан соң кара болыт килеп, ул болыттан җиргә күл бакалары һәм гөберле бакалар ява башлый. Алар кешеләрнең башларына төшә, өйләренә кереп тула, бөтен җир бакалар белән түшәлеп бетә. Бар ризык һәм су савытлары да бакалар белән тулган була. Бераз вакыттан соң бөтен җир бакаларның үле гәүдәләре белән түшәлә, алардан сасы ис таралып, суларга һава калмый. Кыптыйлар тагын Муса галәйһиссәламгә килеп, ярдәм сорап ялвара башлыйлар. Муса галәйһиссәлам иманга килергә дип алардан ныклы вәгъдә алып, Аллаһыга ялварып дога кыла. Әлеге дога аркасында фиргавен халкы бу бәлаләрдән дә азат ителә. Аллаһы Тәгалә җибәргән яңгыр бөтен бакаларны да диңгезгә юып төшерә.

Әмма фиргавен халкы бу юлы да иманга килми. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә яңа афәт җибәрә. Ул – канлы су була. Елгалардагы, чишмә-инешләрдәге сулар, аларның бар эчемлекләре канга әйләнә. Вәгъдәсен күп тапкырлар бозган бу халык тагын Муса галәйһиссәламгә килә, аларны бу бәладан коткаруны сорап, елый-елый ялвара. Муса галәйһиссәламнең догасы аркасында алар бу афәттән дә азат ителәләр.

Бу афәтләрнең һәрберсе Муса галәйһиссәламнең хаклыгын раслый торган ачык галәмәт була. Фиргавен халкы туктаусыз һәлакәткә баруын һәм аннан котылу өчен тиз арада иман китерергә кирәклеген аңлаткан гыйбрәтле бу галәмәтләр Аллаһының кодрәте белән башкарыла. Ләкин, шуңа да карамастан, бу халык тәкәбберләнә, иманга килми. Һәм алар һәр очракта да вәгъдәләрен бозалар, сүзләрендә тормыйлар.

Менә никадәр әхлаксыз була бу халык. Аллаһыга һәм Аның расүленә биргән вәгъдәләрен берничә тапкыр бозганнары өчен бу халык юкка чыгуга дучар була.

### Исраиллеләрнең Мисырдан китүе

Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәлам һәм аның халкын фиргавен золымыннан тулысынча азат итәргә карар иткәч, вәхи вакытында аңа болай дип әйтә:

**«Без Мусага (галәйһиссәлам): «(Сиңа иман китергән) Колларымны төнлә йөрт (Мисырдан алып кит)! Һичшиксез, (фиргавен һәм аның гаскәрләре) сезнең эзегезгә төшәчәкләр», – дип вәхи иттек».**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:52

Муса галәйһиссәлам исраиллеләргә кыптыйлардан, туй үткәрәбез дигән сылтау белән, зәркән (ювелир) әйберләр алып торырга әмер бирә. Аннары, беркемгә дә әйтми, төн караңгылыгында Мисырдан чыгып китәргә куша. Аннан тыш, ул өйләрдә янып торган лампалар калдырырга һәм өйнең хуҗасы чыгып киткәне аңлашылсын өчен аларның ишекләрендә кан белән тамга куярга да куша.

Һәм менә, картлар һәм балаларны исәпләмәгәндә, алты йөз егерме мең санлы исраилле юлга чыга. Һарун галәйһиссәлам алдан, ә Муса галәйһиссәлам – иң соңгы кеше булып бара.

*Дәвамы киләсе санда*

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Кадер кичәсе

Рамазан аен ел буе сагынып көтсәң дә, изге көннәр сизелми дә үтә. Көн арты көн Раббысына тугры булган бәндә кадерле вакытларны изге гамәл, Коръән укуга багышлый. Тоткан ураза калеб-ләрне йомшарта, торган кыям-нар сабыр, әхлаклы итә, укыган аятьләр гафиллектән уята. Тән итагать кыла, тел зикер итә, җан уйлана, гыйбрәт ала.

Кунакның китәр вакытлары җиткәч, кадере арта. Шулай ук Рамазанның ахыргы 10 көне дә безнең өчен аеруча гыйззәтле. Ул көннәрдә иман әһеленең изгелекләре өстәлә, «Рәхмәтенә ирешермен, гөнаһымнан пакыланермен, уттан котылырмын», – дигән өметләр арта. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Аллаһы Илчесе Рамазанның ахыргы ун көнендә башка көннәргә караганда ныграк иҗтиһад, тырышлык күрсәт-те», – дип әйтте.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ул көннәр турында болай дигән: «Рамазанның ахыргы 10 көне – ул җәһәннәм газабыннан котылу көннәре».

Рамазан ае бәгыренең иң күркәм почмагында Коръән иңдерелгән Ка-дер кичәсен яшереп тота. Бер орлык-тан үсеп чыккан агачта меңләгән җимешләр җитешкән кебек, Кадер кичәсенә дә мең ай йөкләнгән.

Бу кичәдә әҗер-саваплар бергә – мең бәрабәрендә языла. Бу кичәнең тулы кадерен һәм кыйммәтен бары ачлыктан нечкәрә-нечкәрә сизгер-ләнгән күңелләр генә аңлый һәм тоя ала. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

**«Хактыр ки, Без Коръәнне (Ләүхел-Мәхфүздән дөнья күгенә) Кадер кичендә төшердек. Сиңа Ка-дер киче дигәне нәрсәне белдерә? Кадер киче – мең айдан да хәерле-рәктер. Ул кичтә һәртөрле эш өчен, Раббыларының рөхсәте белән фәрештәләр һәм Җәбраил галәйһиссәлам иңәр. Ул төннең таңына кадәр иминлек, сәламәтлек булыр».**

«Кадер / Кадер Киче», 97:1-5

### Ни өчен соң ул төн «Кадер киче» дип аталды?

Кадер – «кодрәт» ул, бу төн Аллаһы каршында иң кодрәтле һәм иң хөрмәт-ле төндер. Аның икенче мәгънәсе – «тәкъдир», бу төндә ел әйләнәсенең язмышы тәкъдир кылына. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

**«Ул төндә һәрбер хикмәтле эш бүленә».**

«Духан / Төтен», 44:4

Бу кичәдә фәрештәләр адәм баласының берьеллык тәкъдирен алып киләләр. Соңрак Кадер төнен Коръән иңү белән үзенчәлекле иткән Аллаһы ул төннең тагын бер өстен-леген бәян итеп: «Кадер төне мең ай-дан хәерлерәк», – дип әйтә. Ул төнне догада, гыйбадәттә, зикердә, намазда үткәргән бәндә мең ай гыйбадәт кы-лудан да зуррак әҗер алачактыр. Мең ай ул 83 ел һәм 4 ай була.

Ул төндә җир йөзенә Аллаһы кешеләргә тәкъдир кылган һәрбер ях-шы вә яман эш белән Җәбраил галәйһиссәлам һәм башка фәрештәләр төшәләр. «Ул таң беленгәнче иминлек-тер», ягъни Кадер төнендә җир өстенә төшкән фәрештәләр бәрәкәт, тыныч-лык һәм хәерлелек белән төшәләр. Бигрәк тә ул фәрештәләр Коръән уку-чылар, Аллаһыны зикер итүчеләр һәм гыйлем эстәүчеләр белән бергә була-лар. Шәйтан да ул төнне үзенең мәкерлекләрен кыла алмый.

# Кадер төне кайчан була?

Мөселманнар өчен айлар арасында Рамазан ае, көннәр арасында җомга көне, кичләр арасында Кадер кичәсе иң мөбарәк санала. Кадер кичәсе Ра-мазан шәриф аенда булган бер кичәдер. Шул ук вакытта Рамазанның кайсы кичәсендә булганы төгәл һәм анык рәвештә билгеләнмәгән. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бо-лай дип әйткән: «Кадер төне – Рамазанның ахыргы ун төнендә. Кем аларны уяу үткәрә, Аллаһы аның кыл-ган һәм кылачак гөнаһларын кичерә. Бу да так санлы төндә. Тугызынчы, жиденче, бишенче яки өченчесендә».

Күбесе егерме жидесендә дигән фикердә, чөнки Пәйгамбәребез галәй-һиссәлам мөбарәк төнне соңгы ун төннән эзләде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кадер кичәсен эзләүче кеше аны егерме җиденче төнендә эзләсен», – дип әйтән.

Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе: «Без Рамазан аенда Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә ураза тотканда, уразаның соңгы җиде көне калган иде. Һәм егерме өченче каршы төнгә ул безнең янга төн уртасында намаз укырга чыкты. Егерме дүртенче каршы төнгә ул безнең янга чыкмады, ә егерме бишенчесенә каршы төн ур-тасында чыкты. Аннары мин аңа: «Расүлуллаһ! Бәлки сиңа төнгә намаз-ны үткәрергәдер?» – дидем. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр бу төнне берәр кеше имамга ияреп намаз укыса, бу – төне буе укыган намазга тиң була», – дип җавап бирде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм егерме алтынчы төнгә каршы безнең янга чыкмады. Төннәрнең егерме җиденчесенә кар-



шы төндә ул үзенең хатыннарын, гаилә әгъзаларын һәм башка кешеләрне җыйды һәм намазны шун-дый озак итеп укыды ки, хәтта без сәхәр ашауны калдырудан курыктык. Калган төннәрдә ул безнең янга чыкмады», – дип риваять кылган.

### Кадер төненең үз галәмәтләре бар

Галимнәр билгеләп үткәнчә, Кадер кичәсен кайбер галәмәтләрдән, шул кичкә хас булган аерым билгеләрдән тәгаенләргә мөмкин: бу кичә нурлы, тыныч һәм матур булыр; бик салкын да, бик эссе дә булмас; ул кичтә бо-лытлар йөрмәс һәм җил исмәс, һавадан йолдызлар атылмас, яңгыр яумас, барча җиһанда тылсымлы тын-лык урнашыр. Шул төн артыннан ко-яш нурсыз пакь тулы ай кебек чыгар.

### Кадер кичәсе гыйбадәте

Бу кичә Аллаһының рәхмәте бик мул булган бер кичәдер. Көндез ихтыяҗы булганнарга мөмкин кадәр ярдәм итәргә, авыз ачканда фәкыйрьләрне ашатып-эчерергә, ки-чен Коръән укып, гыйбадәт кылып үткәрергә кирәк. Гыйбадәттә каза на-мазын кылу, Коръәни Кәримнән сүрәләр, догалар уку, тәүбә итү, садака бирү, мөселманнарны сөендерү һәм башка саваплар казану – болар бары-сы да бу кичәгә хөрмәт күрсәтүнең ишарәседер. Хөрмәт күрсәтү гөнаһлы эшләрне эшләмәү белән дә хасил бу-лыр.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр берәү, Аллаһы Тәгаләгә инанып һәм савабы-на өметләнеп, Кадер кичәсен гыйбадәт кылып уздырса, элек кылган гөнаһ-лары гафу ителәчәк».

Бу төндә Пәйгамбәребез салләл-лаһу галәйһи вә сәлләм Гайшә радыяллаһу ганһәгә өйрәтеп калдыр-ган әлеге доганы укырга кирәк:

اَللَّهُمَّ إِنَّكَ عَفُوٌّ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّي

Әллаһүммә иннәкә гәфүввун түхиббуль гәфвә фәәгфүгәннии

«Йә Аллаһым! Син –гафу Итүче һәм (гөнаһлы бәндәләреңне) гафу итәргә яратасың. Гафу итче мине!»

Безнең төп максат булып, бу төнне гыйбадәт һәм зикердә үткәрүе тора.

Пәйгамбәрбез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, дүрт хәлифә радыяллаһу ганһүм һәм соңыннан бөтен Ислам дәүләтләре бу кичәгә олуг хөрмәт күрсәткәннәр, гыйбадәттә үткәргән-нәр.

Безне Рамазаныбызда саулык-сәламәтлектә кавыштырган Аллаһы-бызга мактау, зурлауларыбыз вә шөкерләребез булсын! Тагын да күп еллар дәвамында Рамазаннар мора-дына ирешергә насыйп әйләсен. Әмин!

■ **Сәхифәне «Хозур» редакциясе әзерләде**

## Ураза тоту буенча балалар хөкеме

**Сорау: Балигъылык яшенә җитмәгән бала нинди хөкемдә була?**

**Җавап:** Балигъылык яшенә җитмәгән балага ураза тоту мәҗбүри түгел. Әмма һәр гыйбадәткә кече яшьтән ияләштерү күркәм гамәл. Бу очракта баланың физик мөмкинлекләрен истә тотарга кирәк. Яшь организмга зыян салынырга тиеш түгел.

## Күрем көннәрендә тотылмаган ураза

**Сорау: Хатын-кызлар хәез (күрем) көннәрендә намаз да, ураза да тотмыйлар. Шулай ук, укылмаган намазларын да каза кылмыйлар. Ураза каза кылынамы?**

**Җавап:** Хатыннар хәез көннәрендә һәм бала тапканнан соң чистарыну көннәрендә ураза тотмыйлар, ләкин бу көннәр узгач, калдырган ураза көннәрен каза итеп тотып бетерергә тиеш булалар.

**Сорау: Әгәр хәез хәле ахшам намазына берничә минут кала башланса, ураза бозыламы?**

**Җавап:** Әйе, ураза бозыла, ул көнне каза итеп тотасы була.

## Уразада дару эчү

**Сорау: Ураза вакытында дару эчсәң, ураза бозыламы?**

**Җавап:** Әйе, ураза бозыла. Уразаны түбәндәге дүрт төрле эш боза:

1. Борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару йоту.
2. Бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йоту.
3. Якынлык кылу.
4. Авыз тутырып косу.

## Уразаның файдасы нидә?

**Сорау: Уразаның тәнебезгә файдасы бармы, яки ул бер гыйбадәт буларак кына барамы?**

**Җавап:** Ураза – гыйбадәт, ул Аллаһы Тәгалә өчен башкарыла. Әмма Аллаһы Тәгаләнең өстебезгә йөкләгән һәр гыйбадәтендә тәнебезгә дә, рухи халәтебезгә дә файда бар.

Ураза ризык кабул итүдән генә тыелу түгел, безнең уй-фикерләребез дә уразада. Рамазан аенда кеше төрле начар фикерләрдән, гайбәт сөйләүдән тагын да күбрәк тыелып тора. Шулай ук тәнебез дә пакьләнә: ашказаныбыз ел дәвамында җыелган зыянлы, токсинлы матдәләрдән арына.

Ураза – ул Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләр өчен шөкер итү. Шөкер итү акыл ягыннан да, шәригать буенча да фарыз.

Ураза фәкыйрьләргә мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Байларга ел буе ач торган фәкыйрьләрнең хәленә төшенергә ярдәм итә.



Ураза шәһвәтне (җенси теләкләрне) тыя, чөнки күзгә матур булып күренгән нәрсәләр җенси теләкләрне уята. Ач торганда исә тыелып калып була.

## Онытылып ашау йә эчү

**Сорау: Онытылып берәр нәрсә ашау уразаны бозамы?**

**Җавап:** Юк, бу очракта уразагыз бозылмый, дәвам итеп тотып бетерергә кирәк. Әмма уразалы булуыгыз исегезгә төшү белән, ашаудан туктау тиешле.

## Төшләнү уразаны бозамы?

**Сорау: Йокыдан уянганда мәни (ир-атларның орлыгы) чыкканын белдем. Миңа уразаны каза кыласы буламы?**

**Җавап:** Төшләнү, ягъни поллюция уразаны бозмый. Госел коенып, уразаны дәвам итәргә кирәк.

## Уразалы килеш сагыз чәйнәү, кан алдыру хөкеме

**Сорау: Уразалы килеш сагыз чәйнәргә ярыймы?**

**Җавап:** Уразалы килеш сагыз чәйнәү – мәкруһ (әмма бу очракта сагыздан шикәр кебек тәмләткечләр, яки сагызның кисәкчекләре бүленеп чыкмаска тиеш. Сагызда нинди генә булса да тәм, ис сизелсә, ул очракта ураза бозыла). Шунысын да истә тотарга кирәк: буш карынга сагыз чәйнәү медицина күзлегеннән караганда да хупланмый: сагыз чәйнәгәндә ашказаны согы бүленеп чыга. Бу исә төрле авырулар барлыкка килүгә сәбәп булырга мөмкин.

**Сорау: Уразада авызны теш пастасы белән чистартырга ярыймы?**

**Җавап:** Бу – мәкруһ гамәл. Теш пастасын кулланган очракта, авызда аның тәме беткәнчегә кадәр су белән чайкатырга кирәк булачак.

**Сорау: Укол ясатуның хөкеме нинди?**
**Җавап:** Туклыклы матдәләре булмаган (глюкоза, физраствор) уколлар уразаны бозмый.

**Сорау: Уразалы килеш кан алдыру ярыймы (хиджама)?**
**Җавап:** Кан алдыру уразаны бозмый, чөнки Пәйгамбәребез галәйһиссәлам уразалы килеш, ихрамда чакта да кан алдыра торган булган.

## Тәһарәт алганда су йотылса нишләргә?

**Сорау: Тәһарәт алганда, яки госел коенганда ялгыш кына су йотылса, уразаны дәвам итәргә ярыймы?**

**Җавап:** Бер тамчы су йоту уразаны боза. Ялгышлык белән кылынганлыктан, бу көннең уразасын каза кылырга тиешле. Уразаның әдәбе буенча, бу көнне, ифтарга кадәр, уразадагы кебек, ашамыйча үткәрү мөстәхәб гамәл булып тора.

## Намаз укымасам, ураза тота аламмы?

**Сорау: Мин намаз укымыйм, әмма ураза тотам. Андый ураза кабул кылынамы?**

**Җавап:** Ислам дине 5 баганага нигезләнгән. Намаз һәм ураза – алар икесе ике гыйбадәт. Шуңа күрә, сез намаз укымасагыз да, уразагыз, иншәАллаһ, кабул булачак.

■ **Җаваплар «Рамазан. Ураза: еш бирелә торган сораулар» китабыннан алынды**

# Уразаның үзенчәлекләре

Ураза гарәпчә «саум» дип атала. «Саум»ның лексик мәгънәсе «берәр нәрсәдән ерагаю, читләшү, берәр нәрсәгә каршы тору» дигәнне белдерә. Менә, мәсәлән, Аллаһы Тәгалә хәзрәти Мәрьям турында болай дип әйткән:

**«Мин Аллаһы ризалыгы өчен һичкем белән сөйләшмәскә нәзер әйттем, шуның өчен бу көндә һичкем белән сөйләшмим».**

«Мәрьям», 19:26

Уразаның шәригатьтәге мәгънәсе ураза тотучы кешеләрнең үзләрен икенче фәҗердән (таң атканнан) алып, кояш батканчыга кадәр ашауэчүдән һәм җенси якынлыктан тыюларын белдерә.

Икенче фәҗер – «имсак» вакыты. Гарәп телендә «имсак» үз-үзеңне тыю дигән мәгънәне белдерә. Имсак вакытында ястү намазының вакыты чыгып, иртәнге намазның вакыты керә.

Шушы вакытта сәхәр ашалып бетеп, ураза башлана. Моннан соң ураза тотучы кеше үзен ашаудан да, эчүдән дә, җенси якынлыклардан да тыя.

Кояш баткан вакыт ифтар вакыты була. Бу вакыттан алып, ураза тоткан кешеләр өчен тыелган нәрсәләр рөхсәт ителә. Ахшам намазының вакыты да кергән була.

Имсак мофтыйрат (уразаны боза торган) дип аталган нәрсәләрдән нәфесне чынлыкта яки хөкем рәвешендә тыя. Ялгышып яки онытылып китеп берәр ризык алып капкан чакта хөкмән (хөкемле) имсак барлыкка килә һәм ураза бозылмый.

Имсакның капма-каршысы – ифтар. Бер дә ураза тотмау да – ифтар, уразадагы кешеләрнең, кояш баткач, авыз ачулары да ифтар була.

Ураза тотканда уразаны бозарлык берәр нәрсә эшләү дә ифтар санала. Ифтар кылган кеше дә, уразаны бозган нәрсәләрнең һәркайсы да مُفْطِرْ «мофтыйр» дип атала. Барысы бергә مُفْطِرَاتْ «мофтыйрат» дип исемләнә.

Рамазан аен شَهْرِ صِيَامْ «Шәһри Сыйам» дип әйтәләр, Ураза бәйрәмен, тыелган вакыт тәмамланганга күрә, عيد فِطْرْ «Гийд әл-Фитыр» (ураза тәгәлләнү бәйрәме) дип атыйлар.

## VIII Республикакүләм ифтар старт алды. Фоторепортаж








# Рамазан уразасының фарыз булу хикмәтләре

**Уразаның канунлаштырылуында шактый хикмәтләр бар:**

## Ураза – бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер итү чарасы

Нигъмәтләр өчен шөкер итү акыл белән дә, шәригать буенча да фарыз. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә ураза турындагы аятьтә:

**«Шаять, Аллаһыга шөкер итәрсез!»** – дип әмер итеп, шуңа ишарәләгән;

## Фәкыйрьләргә карашны үзгәртә

Ураза фәкыйрьләргә мәрхәмәтле һәм шәфкатьле булырга өйрәтә. Байларга ел буе ач торган фәкыйрьләрнең хәленә төшенергә ярдәм итә;

## Рухи чистарыну чарасы

Уразаның рухи саваплары, гөнаһлардан саклану кебек фазыйләтләре дә, гәүдәне чистарту (арындыру) һәм кайбер хасталыклардан саклау кебек матди файдалары да бар.

Уразаның ашказанын сәламәтләндерүе һәркемгә мәгълүм. Мәсәлән:

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгәнчә, бер хәдистә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ураза тотыгыз, сәламәт булыгыз», – дип әмер иткән.

## Ураза шәһвәтне тыя

Ураза шәһвәтне (җенси теләкләрне) тыя. Чөнки күзгә матур булып күренгән нәрсәләр җенси теләкләрне уята. Ач торганда исә тыелып калып була.

Бу очракта ураза гөнаһлардан сакланырга ярдәм итә торган чара. Мәсәлән, Габдулла радыяллаһу ганһе болай дип аңлаткан: «Без Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кулы астындагы бер төркем яшьләр идек. Тик безнең өйләнергә бернинди мөмкинлегебез дә юк иде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә: «Әй, яшьләр! Өйләнергә мөмкинлеге булганыгыз өйләнсен, чөнки өйләнү күзне харамнан саклый торган иң яхшы чара һәм җенси әгъзаларны да саклый. Өйләнергә көчегездән килмәсә, ураза тотыгыз, чөнки ураза кешенең җенси теләкләрен тыярга ярдәм итә», – дип боерды.

Дин галимнәре фикеренчә, җенси теләкне тыю өчен, көндез ураза тотарга, ә төннәрен гыйбадәт кылырга кирәк, чөнки ураза һәм гыйбадәтләр җенси теләкләр турында онытырга ярдәм итә. Әгәр син: «Бер кеше ураза тота, төнлә тора, күп ашамый. Әмма нәфесе һаман да җенси теләкләрдән аерылмаган була», - дисәң, «Бу, беренче чиратта, җенси теләкләрнең артык булуыннан килә. Мондый кешегә без җенси теләкләрен тыю өчен даими кайгы-хәсрәтләр һәм үлем, әҗәлнең якынайганы турында уйланырга, озын гамәлләрне кыскартырга, Раббыбызны күргәндәгедәй халәтләрен дәвам иттерергә һәм гыйбадәтләрен дәвамлы рәвештә кыскартырга тырышуын киңәш итәбез».

Шуны белергә кирәк: барлык кешеләрнең дә тырышулары ике төрле нәрсәгә бәйле:

1. Ашау-эчү теләге.
2. Җенси теләк.

Уразаның, әлеге ике теләкне тыеп, кешене тәкъвалыкка ирештерүеннән шикләнергә ярамый.

## Ураза тәкъвалыкка илтә

Ураза тоткан кеше, Аллаһы Тәгаләнең үзенә хәләл итеп биргән нигъмәтләреннән бары тик Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешүне өметләнә, хәсрәткә төшерүче газапларыннан куркып, үзен тоткарлый алганча тоткарлый, тыя алган кадәр тыя.

Аллаһы Тәгалә харам кылган нәрсәләрдән үзен саклау, һичшиксез, тагын да яхшырак була. Тәкъвалык шушы була инде.

Мәсәлән, ураза турындагы аятьнең ахырында Аллаһы Тәгалә: «Шаять, Аллаһыга шөкер итәрсез!» – дип әмер иткән.

Раббыбыз «Әл-Бәкара» сүрәсенең 21 нче аятендә:

**«Әй, кешеләр! Аллаһы газабыннан куркучы булу өчен, сезне һәм сездән элек булган кешеләрне халык кылучы Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз!»** – дип әмер иткән.

Югарыда искә алган ураза турындагы аятьтә дә:

**«Әй, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз!»** – дип боерылган.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Бу аятьләрдән аңлашылганча, барлык гыйбадәтләрнең дә, бигрәк тә, уразаның дәвамлы булуыннан тәкъвалык барлыкка килә. Ягъни барлык гыйбадәтләрне дә дәвамлы башкарган кеше тәкъвалыкка (Аллаһыдан куркуга, Аллаһыны ихтирам итүгә) ирешә. Димәк, гыйбадәт кылмаган кешеләр тәкъва булмый, чөнки тәкъва – гыйбадәтнең нәтиҗәсе. Бигрәк тә бу аятьләрдән тәкъвалыкка ирештермәгән ураза һәм башка гыйбадәтләрнең Аллаһы каршысында рөхсәт ителмәве аңлашыла. Мәсәлән: Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгән бер хәдистә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ялган сөйләүдән һәм ялган белән гамәл кылудан туктамаган кешенең, ураза тотам дип, ашауэчүеннән калуына Аллаһы мохтаҗ түгел».

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешеләрнең итләрен ашаганнар (гайбәт сөйләгән) ураза тотмадылар», – дип әйткән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгән бер хәдистә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ураза ашау белән эчүдән генә өзелеп тору түгел ул. Ураза кирәкмәгән сүзләрдән һәм гамәлләрдән, җенси теләкләрне кузгатучы сүзләр һәм гамәлләрдән тыелуны да белдерә. Әгәр бер кеше сине сүгә яки сиңа каршы белмичә хәрәкәт итә башласа, син «мин ураза тотам (синең сүзләреңне ишетмәм)» дип әйт».

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөньяда никадәр ураза тотучы бар, тик аларның уразалары (харамнан сакланмаганнары сәбәпле) бары тик ач торудан гыйбарәт. Дөньяда төннәрен торып никадәр намаз укучы бар, тик аларның кыямнары бары тик йокысызлык булып кына кала», – дип әйткән.

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять ителгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдистә: «Биш нәрсә ураза тотучының авызын ачтырыр (савабын бетерер) һәм тәһарәтен(ең камиллеген) бозар. (Болар): ялган, гайбәт, сүз ташу, җенси теләк белән карау һәм ялганлап ант итү», – дип кисәткән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе әйткән: «Гайбәт уразаны ерта, истигъфар (гафу итүне сорау) аңа ямаулык сала. Һәркайсыгыз, иртәгә Ахирәткә уразасы ямалган килеш барырга көченнән килсә, моны эшләргә тырышсын».

Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһе болай дигән: «Ураза тотканда, колагың, күзең һәм телеңне ялганнан һәм барлык харамнардан тый (үзеңне сакла). Хезмәтчеләреңне дә җәберләмә, уразалы көнеңдә сабырлы һәм тыныч бул, уразалы көнең белән ураза тотмаган көнең охшаш булмасын».

Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Ураза тотканда, харамнардан көчең җиткән кадәр сакланырга тырыш».

Үзе дә ураза тоткан көннәрендә өенә кайтып гыйбадәт кыла торган булган, намазларга барыр өчен генә өеннән чыккан.

Имам Мөҗаһид рәхмәтуллаһи галәйһи болай дип әйткән: «Ике сыйфат бар. Алардан сакланган кешенең уразасы бозылмас. Болар – гайбәт һәм ялган».

Әбү Әл-Алийә дә: «Ураза тоткан кеше гайбәт сөйләгәнчегә кадәр гыйбадәтендә булыр», – дигән.

Хөзәйфа бине Йәман радыяллаһу ганһе болай дигән: «Узып барган хатын-кызның артыннан нәфесле күз белән карап калган кешенең уразасы бозылыр».

Ураза тотучы кешегә, дөнья һәм Ахирәтен югалтмау өчен, әдәп сакларга, уразасын күрсәтмәлелектән (риядан) һәм кеше сүзеннән сакларга, барлык гыйбадәтләрен дә тиешенчә үтәргә кирәк. Чөнки Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен кылынмаган, бары тик кешеләргә күрсәтү өчен генә эшләнгән гамәлләр бик күп газапларга дучар итәләр.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең догасын китерәбез: «Әй, Аллаһым! Телемне ялганнан, йөрәгемне икейөзлелектән, гамәлләремне риядан (кешеләргә күрсәтү өчен эшләүдән) һәм күзләремне хыянәтле караудан пакьлә! Чөнки Син күзләрнең хыянәтен һәм йөрәкләрнең серен беләсең!»

■ **dum.rt**

# Телебез – милләтебез язмышы

**Тарих гомер-гомергә иң кызыклы фәннәрнең берсе булып кала бирә. Татар халкы да «Үткәнен белмәгәннең – киләчәге юк», дип юкка гына әйтмәгәндер. «Дин вә Мәгыйшәт» редакциясе дә тарихыбызда булган кайбер вакыйгалар белән кызыксынып, тарих фәннәре кандидаты Әскар Гатин белән әңгәмә корырга булды.**



**– Рәсәйдә иң беренче тапкыр халык санын кайчан алалар? Татарларны беренче халык санын алуда кем дип язганнар?**

– Рәсәйдә урта гасырлар һәм яңа заманда халыкны төгәл санап тору бары тик XIX гасырның ахырында гына башлана. Аңа тикле алпавытлар һәм дәүләткә хезмәт итүче җирбиләүчеләр санын, дәүләт җирендә яшәүче халыкның санын кирәк булган вакытта гына теркәп барганнар. Шулай да, ул теркәү төгәл булмаган. XVIII-XIX гасырларда хөкүмәт ревизияләр үткәргән: алар күбесенчә ирләр санын исәпләр өчен үткәрелгән, чөнки ирләрнең санын белү – салым җыю һәм армиягә рекрутларны алыр өчен кирәк була. Ләкин анда аларның гаиләләре турында да мәгълүмат җыелган.

Инде капиталистик чорда, авыллардан шәһәрләргә күпләп күченү башлангач, халыкның тормышын статистик яктан төгәл өйрәнер өчен мөкинлекләр тугач, 1897 елда халык санын алу үткәрелә. Аңа әзерлек эше һәм аны үткәрү турындагы фикер 1870 елда ук әйтелә. Әлбәттә, бу халык санын алу Казан, Ырынбур, Өфе губерния-ләрендә яшәүче татарлар арасында каршылыклы фикер уята. Кайбер кешеләр бу халык санын үткәрү максатын аңламыйча, моны чукындыру белән бәйлиләр һәм аңа каршы имеш-мимешләр тарата башлыйлар. Ул вакытта урыс миссионерларыннан курку халыкта бик көчле була әле. Кайбер авылларда кешеләрне яздырып алуга каршы чыгу очраклары да теркәлгән. Шул вакытта халык санын алуның максатларын аңлатыр өчен җирле муллаларны кулланырга тырышалар. Мәсәлән, Бөгелмә өязендә шундый хәл була: анда җирле имам һәм ахун Гыйльман Кәримовны бу эшкә тарталар.

**– Бүгенге көндә татар теле язмышына куркыныч янаганын исәптә тотып, телне саклап калу, алдагы буыннарга тапшыру өчен татар гаиләләре үз тарафларыннан нинди өлеш кертә ала?**

– Мин бу сорауны күбрәк фәлсәфи сорау буларак карыйм, чөнки гаилә төп яшәү формасы буларак юкка чыккан вакытта, гаиләдән артык күп нәрсә көтеп булмый. Без һаман гаилә дигәндә ниндидер бер иске тормышны күз алдыбызга китерәбез: берничә буын бергә бер өйдә яшәгән, ирле-хатынлы, бергә хуҗалык алып барган гаилә. Әйе, андый үрнәк булырлык гаиләләр бездә бар, аз да түгел, ләкин чынбарлыкта алардан башка без ни күрәбез: иреннән аерылышкан яисә баласын ялгыз тәрбияләүче хатынкызлар бик күп, гаилә коручылар арасында хәзер аерылышулар бик күп, әле моңа тагын катнаш никахларны өстәп куйсак – менә сезгә катлаулы һәм камил булмаган бер чынбарлык. Бу бит иске тормыштан бөтенләй аерылып торган чынбарлык! Совет чорында безнең милләтебезгә өч бик яман сыйфат үтеп керде: беренчедән, Ислам дине юкка чыгып, милләтнең нигезе югалды; икенчедән, гаиләдә һәм җәмгыятьтә ирләр үз урынын югалтты, ирлек сыйфатлары бетте, ир балаларны ир булып тәрбияләү юкка чыкты; өченчедән, тормышыбыз нык үзгәрде, яңа техник җиһазлар һәм яңа яшәү шартлары барлыкка килде – борынгы йолалар, тормыш гадәтләре үзеннән-үзе юкка чыгып бара. Әйе, кемдер минем бу сүзләремне яратмас. Күпчелек кешеләрнең күңелләренә бу хуш килмәс! Безнең хәзерге вакытта тактик яктан ике генә котылу юлыбыз бар: беренчесе – ул хәзерге заман технологияләрен кулланып, татар телендә мәгълүмати мохит тудыру: электрон газеталар, хәбәрләр дөнья тормышын ТАТАРЧА яктыртырга тиеш, гел татарга татар турында гына сөйләп, язып утыру – ул үлемгә илтә торган юл; икенче юл авыррак – телебезне мәдәният аркылы таныту, мәдәниятебезгә тирән тикшерү үткәрергә кирәк. Безнең элеккеге мәдәниятебез ислам мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә торган – бу бит үзе бер мирас! Язучыларыбыз арасында классик булган шәхесләр бар, ә алар язган әсәрләрдә бик тирән уйлар, фикерләр бар – шул әйткән фикерләрне күтәрергә кирәк.

**– Кызганычка, хәтта кайбер татар гаиләләрендә дә балаларның күбесенчә рус телендә сөйләшкәнен, үз ана телләрен начар белгәнен күрәбез. Әйтегез әле, биредә гаеп күбесенчә ата-аналардамы яки җәмгыятьтә, мәктәптәме?**

– Мәктәп балаларга тәрбия бирә алмый. Аның максатлары башка төрле. Әйе, безнең җәмгыятебез – Рәсәй элеккеге СССРдан чыккан кешеләр – һаман тәрбияне мәктәпкә борып калдыра. Ләкин читтәге бер укытучы ят балаларга нинди тәрбия бирә ала? Кызганычка, хәзерге вакытта балаларның хәле асралган өй мәчесенә охшаш: хуҗасы аны ашата-эчертә. Берәр нинди хәл булса, орышу белән бетә. Бар тәрбия шул. Әле гаилә тулы, ягъни ирле-хатынлы булсалар, андый гаиләләрдә күп ирләр тәрбиядән ерак тора: хатын-кыз өй эшен эшли, эшкә чаба, ә ире пешкән ризыкны көтеп утыра, телевизор янында вакытны үткәрә. Әлбәттә, бу хәл 90нчы елларда гына барлыкка килмәгән, аның тамырлары совет чорындагы тәрбия системасында. Советлар дәүләте балаларны ата-анадан махсус аерган, чөнки яшь кешеләр эштә булырга тиеш, ә балаларны карау вазифасы балалар бакчасына, пионер аланнарына, мәктәпкә күчкән. Моны идеологик яктан бик матур итеп, күз буяп аңлата да алганнар: ата-ана яңа совет кешесен үстерер өчен тиешле тәрбияне һәм белемне бирә алмый. Әлбәттә, җәмгыятьне бөтенләй үзгәртеп корыр өчен белем системасы кулланылган. Ул дин белән көрәшү, яңа идеологияне яшь буыннарга сеңдерү эшендә бик актив эшләгән. Нәтиҗәдә, 1940 – 1960 елларда тоташ мәгариф системасы җәмгыять карашларын үзгәртә алган. Моңа тагын татар халкының борынборыннан белемгә омтылуы да өстәлгән – генетик тамырларыбызга сеңгән белем алуда тырышлык совет чорында менә дигән файдалы сыйфат була! Тик милләтебез өчен түгел, ә тормышны үзгәртеп коручы дәүләт кулында. Безнең халкыбыз совет чорында телен дә, мәдәниятен дә, йолаларын да, барысын югалтып бетерә! Инерция (сүлпәнлек, хәрәкәтсезлек, ред.) белән яшәгән авыл халкы гына татар телен саклап килгәнгә, халкыбызда бераз татар рухы калган, ләкин ул да бик нык какшаган. Рухи нигезен дә без югалттык. Бу, чынлыкта, бик зур фаҗига! Моны аңламыйча, уйламыйча, алга яшәү һәм котылу юлын эзләп булмый! Авыру үзенең авыру сәбәпләрен аңлаган хәлдә генә дәваны таба алыр. Сез биргән сорауга килгәндә, без хәзер беркемне дә гаепли алмыйбыз. Гаепләү безгә ни бирәчәк? Буш сүзләр генә. Әйе, ата-аналар гаепле, ләкин аларны шундый булдырган дәүләт юк инде. Мәктәп тә гаепле, ләкин ул мәктәпне үзгәртеп бетерү ни бирер? Яңа буынны алга алып баручы әйдәман кешеләр кирәк! Алар гына юлын күрсәтеп, шул юлга башкаларны күндереп милләтебез бара алыр. Без үзебезгә хәерле юлбашчыларны Аллаһыдан сорарга тиеш!

**– Тирән эчтәлекле әңгәмә өчен рәхмәт сезгә!**

**■ Әңгәмәне «Дин вә Мәгыйшәт» редакциясе әзерләде**

# Сүз – куәтле чара

Тел – ул Аллаһының бөек нигъмәте һәм олы сәнгате. Ул тормышыбызны күпкә җиңеләйтә. Аның аркасында үз хисләребезне, тойгыларыбызны, теләкләребезне белдерә алабыз. Сүз – хәзерге мәгълүмат заманында бик куәтле чара (ә төгәлрәк итеп әйткәндә – корал) булып тора. Кайвакыт кешене көч кулланып яралаганга караганда, аны сүз белән күпкә тирәнрәк яраларга мөмкин. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бер сәхабәсе: «Әй, Аллаһының Илчесе, минем өчен иң куркыныч әйбер нәрсә?» – дип сораган. Пәйгамбәр галәйһиссәлам кулы белән теленә күрсәткән.

Икенче хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Кешенең йөрәге тугры булганчыга кадәр иманы дөрес булмас. Теле тугры булганчы йөрәге тугры булмас» (Әхмәд).

Хөрмәтле мөселманнар! Кешенең бөтен әгъзалары тел белән бәйләнгән, чөнки Аллаһының Расүле галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Кеше иртә белән йокыдан торганда аның бөтен әгъзалары, телгә мөрәҗәгать итеп: «Безнең хакта Аллаһыдан курык, чөнки барыбыз сиңа бәйле. Син тугры булсаң, без дә тугры булырбыз. Син тугрылыктан тайпылсаң, без дә тайпылырбыз!» – дип әйтә» (Тирмизи).

Мөхтәрәм җәмәгать! Шушы олы хәдис турында тирәнрәк фикерләсәк иде. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять итә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Дөреслектә, берәү бер сүз әйтсә һәм Аллаһы шушы сүзе белән риза булса, аның дәрәҗәсен күтәрер. Әгәр берәү бер сүз әйтсә һәм Аллаһы шушы сүзе өчен аңа ачуланса, аның дәрәҗәсен төшерер» (Бохари, Мөслим).

**■ Тимергали хәзрәт Юлдашев, «Саләх» мәчете имам-хатыйбы**

# Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең нәселе Казанда яшәгәне дөресме?





X гасырда, болгарлар Ислам динен кабул иткәннән соң, алар аны бөтен Идел буена тарата башлый. Алтын Урда чорында, Хәрәзмиләр мәдәнияте йогынтысы белән, бу тагын да көчәя төшә. Чама белән якынча XIV гасырда Болгар вилаяте, ә аның белән берлектә Казан һәм төньяк территорияләр ислам таратуның үзәкләренә әйләнә.

Әлеге чорда бирегә сәидләр – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселеннән булган кешеләр күченеп килгән дип санала. Алар яңа урыннар – ханигаһлар, мәктәп-мәдрәсәләр ачуда үз өлешләрен керткәннәр. Яңа мәчет-мәдрәсәләр, Болгар һәм Казан мунчалары, Алтын Урдадагы кебек сарайлар – Хәрәзмиләр мөселман мәдәниятенең көчле йогынтысы астында булганнар. Алга таба Казан ханлыгында, Кырым аша, Госманлы солтаннар дәүләтенең тәэсире сизелә башлый. Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле хезмәтендә түбәндәге мәгълүматны калдырган:



بسم الله الرحمن الرحیم

القسم الثانی من کتاب مستفاد الاخبار فی احوال قزان وبلغار روسیه طائفه سی
سنة احدی وستین وتسعمائة حدودنده تاتار طائفه سینه غلبه قلب بلدهٔ قزان نی
نواحی بیله ضبط ایتدکلرنده قلعه داخلنده سکز منارهلی بر مسجد جامع وتاجیك
جرماغی دیمکله معروف محلده بنه بر مسجد ومدرسه اولب علماء واشراف
عباسیه وسادات علویه دن ونچه اشخاص وآنلرننك رئیسی نقیب الاشراف
عنواننده ملا شریف قل نام بر ذات بولوب اسلام خانلری واهالی بلاد نظرنده
زیاده معزز ومحترم ایدی روسیه کنازلری قزان خانلرینه ایلچی ییباروب

«961 ел азагында (Григориан календаре буенча 1552 ел) Рәсәй Казан шәһәрен һәм аның җирләрен яулап алып, татарларны җиңде. Биредә сигез манаралы җәмигъ мәчете бар иде. Моннан тыш, «Таҗик чокыры» дип аталган урын янында тагын бер мәчет һәм мәдрәсә була. Анда галимнәр, габбасилар нәселеннән булган вәкилләр (габбасиларның шәрифләре) һәм мулла Шәриф Кол ( сүз Кол Шәриф турында бара) җитәкчелегендә, Гали нәселеннән булган сәидләр бар иде. Мөселман ханнары һәм шәһәр халкы арасында бу шәхес зур хөрмәткә һәм абруйга ия булган» (Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». Казан, 1900. 2 б.).

Кызганычка, сакланып калган тарихи чыганакларның бик аз булуы сәбәпле күп әйберләр сер булып кала. Без сәид (сәид, сәйид, сәййид) дип хөрмәтләп, Мөхәммәд галәйһиссәламнең нәселеннән булган кешеләргә мөрәҗәгать иткәннәрен беләбез. Ул гарәп теленнән әфәнде, җитәкче, мөкатдәс, күркәм дигән сүзләрне белдерә.

Шәриф (шериф) сүзе намуслы, гадел, күренекле дигәнне аңлата. Бүгенге көндә бу сүзләрнең икесе дә Расүлебез галәйһиссәламнең кызы Фатыйма радыяллаһу ганһә һәм кияве Гали радыяллаһу ганһе нәселеннән булган кешеләргә эндәшкәндә кулланыла. Исламга кадәр сәид һәм шәриф дип, гарәпләр данлыклы кешеләргә дәшә иделәр. Ислам килү белән бу сүзләр Мөхәммәд галәйһиссәламнең Фатыйма радыяллаһу ганһә һәм Гали радыяллаһу ганһедән булган оныклары һәм оныкчыкларына карата кулланыла башлады.

Сәидләргә кайвакыт Габделмотталибның башка уллары: Габбас, Хәмзәнең нәселеннән булган кешеләрне дә кертәләр иде. Ә әшраф (шәриф сүзенең күплек санында кулланылышы) сүзе, күп очракта, сәдат (сәид сүзенең күплек санында кулланылышы) сүзенең синонимы буларак кулланылып, аерым бер төр сәидләрне билгеләр өчен алынган.

Шул рәвешле, Казанда пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселеннән булучылар – сәидләр яшәгән һәм алар Казан ханлыгында зур абруйга ия булган. Моннан тыш, Казан сәидләренең һәм шәрифләренең башлыгында нәкиб әл-әшраф торган. Билгеләп үтәргә кирәк, нәкиб әл-әшраф вазифасы Габбасилар хәлифәте вакытында барлыкка килгән. Бу вазифа илдәге сәидләр һәм шәрифләр санын тикшереп торудан гыйбарәт булган.

Әлеге институт Сефевид Иранлыгында һәм Госманлы солтаннар империясендә дә булган. Казан ханлыгының соңгы нәкиб әл-әшрафы – 1552 елда үзенең шәкертләре белән Казанны саклап, батырларча һәлак булган танылган мулла Кол Шәриф иде. Казан ханлыгында сәидләргә карата булган хөрмәт хакында, Мәскәү дәүләтендә Рим империясе илчесе Сигизмунд фон Герберштейн (1486-1566) сүзләреннән беләбез:

«Ул (сәид) аларда (татарларда) шундый хөрмәт казанган ки, алар якынлаша башлагач, хәтта патшалар (ханнар) аны каршыларга чыга, аягүрә халәтендә атта утыручыга кул бирә һәм башын иеп, иреннәрен аның кулына тидерә. Моны эшләү бары тик патшаларга гына рөхсәт ителә, чөнки кенәзләр аның кулына түгел, ә тез буынына, мәшһүр кешеләр исә аякларына, ә инде гади халык аның күлмәгенә яки атына гына тотына» (Сигизмунд фон Герберштейн. Мәскәү эшләре турында язулар. СПб. 1908. 153 б.).

Шуның өчен, Татарстан җирләрендә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең нәселеннән булучыларның яшәүләре (ә бәлки хәзерге көндә дә яшиләрдер) белән без горурланырга тиеш. Ә Казанның, Кремльдә урнашкан, иң



матур мәчете Казан ханлыгы сәидләре һәм шәрифләренең башлыгы, Казанның данлыклы яклаучысы, шагыйрь, галим, дәүләт эшлеклесе – сәид Кол Шәриф исемен йөртә.

■ **Мөхсин Нурулла язмасы,**
**islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**

# Мәрхәмәтлелек вә йомшак күңеллелек

Ислам динендә шәфкатьле вә ярдәмчел булуга мәрхәмәт диелә.

Аллаһы Тәгалә Рахман вә Рахим, ягъни колларына дөньяда да, Ахирәттә дә бик шәфкатьле вә миһербанлыдыр. Шуның өчен мәрхәмәт – ул илаһи бер тойгыдыр, ләкин ул Аллаһының сыйфатына тиң түгел. Мөселман каты йөрәкле, каты күңелле түгел, киресенчә, мәрхәмәтле вә йомшак күңелле булырга тиеш. Аллаһының мәхлүкъларына карата күңелендә шәфкать вә мәрхәмәт йөрткән кеше – өстен кешедер. Бу кеше Аллаһының Рахман вә Рахим сыйфатларыннан өлеш алган өчен һәртөрле хөрмәткә лаектыр. Аллаһының рәхмәте вә мәрхәмәте чиксездер. Аларның бик кечкенә өлеше генә кешеләргә бирелгән.

### Йомшак күңелле булыйк

Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Аллаһы Тәгалә рәхмәт вә мәрхәмәтен йөз өлешкә бүлде. Туксан тугыз өлешен Үзе янында калдырып, бер өлешен генә җир йөзенә төшерде. Менә бу бер өлеш мәрхәмәт аркылы кешеләр бер-берләренә мәрхәмәт күрсәтер», – дип әйткән.

Каты күңелләләр, башкаларга золым вә газап кылучылар дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле була алмас. Ислам дине каты күңелле булуны харам кылгандыр.

Беркөнне Пәйгамбәребез оныгы Хәсәнне кочаклап үпкәнен Әкра бине Һәбис исемле иптәше күрде һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә шулай диде: «Димәк ки, сез балаларны үбәсез икән. Минем ун балам бар һәм мин аларны беркайчан да үпкәнем булмады». Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу кешегә исе китеп карады һәм шулай диде: «Мәрхәмәт итмәгән кешегә мәрхәмәт кылынмас». Башка бер хәдисендә дә Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Кешеләргә мәрхәмәт кылмаган кешегә Аллаһы да мәрхәмәт кылмас». Бу хәдисләрдән күренгәнчә, мәрхәмәтсез вә каты күңелле кешеләргә Аллаһының да мәрхәмәте булмас.

Ислам дине буенча мөселманнар бер гәүдәнең әгъзалары кебектер. Гәүдәнең әгъзалары бер-берләренә булышып, ярдәмләшеп, гәүдәнең сәламәтлеген саклаган кебек, мөселманнар да бер-берләренә таянып, бер-берләренең кайгыларын уртаклашып, мәрхәмәт вә шәфкать күрсәтеп, араларындагы сөю вә хөрмәтне арттырып, барлыкны дәвам иттерергә тиешләр.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә түбәндәгечә боера:

**«Рәхмәтем вә мәрхәмәтем һәрнәрсәне каплады».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:156

Ислам дине тарафыннан безгә бирелгән мәрхәмәт бөтен кешелекне, хәтта бөтен барлыкны каплар. Мөселман булган кеше кешелеккә карата гына түгел, хайваннарга да мәрхәмәтле булыр. Зарарсыз хайваннар үтерелмәс. Ач вә сусыз калдырып, яисә юкка кыйнап, хайваннарга газап кылынмас. Ислам динендә кешеләрнең генә түгел, хайваннарның да хакы вә хокукы бар.

Берзаман Пәйгамбәребез сәхабәләренә җәһәннәмле булган бер хатын турында сөйләгән. Бу хатын, мәчесенә ачуланып, аны бер бүлмәгә ябып куйган. Мәчесенә аш та, су да бирмәгән, вә шулай итеп, мәченең ачка үлүенә гаепле булган. Бу хатын мәчесенә мәрхәмәт кылмаганы өчен җәһәннәмле булган. Югарыда әйтеп үткәнебезчә, Ислам дине безне кешеләргә генә түгел, бөтен җан ияләренә дә шәфкатьле вә мәрхәмәтле булырга өнди.

# Ярдәмләшү вә юмартлык

Юмартлык – үзенә нинди дә булса файда килүне өмет итмичә мохтаҗларга ярдәм итү.

Бер үк җәмгыятьтә төрле кешеләр яши. Алар арасында көчлеләр дә, зәгыйфьләр дә, байлар һәм ярлылар, кечкенәләр вә олылар, галимнәр вә наданнар да бар. Кеше дөньяда никадәр бай, никадәр көчлекуәтле булса да, берүзе генә яши алмас иде, ул башка кешеләрнең ярдәменә дә мохтаҗ. Шуның өчен динебез үзара ярдәмләшүне фарыз кылган.

Ярдәмләшү вә юмартлык Коръәндә дә фарыз кылынган вә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисләрендә дә макталган.

Юмартлыкның киресе булган саранлык динебездә харам кылынган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам бер хәдисендә түбәндәгечә боерган: «Юмартлык – ботакларын дөньяга сузган җәннәт агачларыннан берседер. Кем бу ботакларның берсенә тотынса, ул аны җәннәткә тартыр. Саранлык – ботакларын дөньяга сузган җәһәннәм агачларыннандыр. Кем бу агачның ботагына тотынса, ул ботак кешене җәһәннәмгә тартыр».

Ислам тарихында иң зур юмартлык күрсәткән кеше, шик тә юк, Пәйгамбәребез Мөхәммәдтер. Аның сәхабәләреннән Җәбир радыяллаһу ганһе шулай дип сөйләгән: «Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнән нәрсә сорасаң да, һич кире бормый иде. Булса бирә, булмаса бирергә вәгъдә кыла иде».

Кешеләр арасында сөю вә мәхәббәтне арттырган иң мөһим нәрсә – үзара ярдәмләшү һәм юмартлыктыр. Аллаһы сөйгән колларын юмартлык тойгысы белән яраткан.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә:

«Шик тә юк, юмарт кеше Аллаһыга, кешеләргә вә җәннәткә якын, җәһәннәмнән еракты р. Саран кеше исә Аллаһыдан, кешеләрдән вә җәннәттән ерак, җәһәннәмгә якындыр», – дигән.

### Динебездә ярдәм ике өлешкә бүленеп карала

Матди ярдәм: мал вә акча белән ясалган һәртөрле ярдәмнәр;

Мәгънәви ярдәм: кайгылы кешеләрне тынычландыра торган сүзләр белән юату, кешеләрнең хаталарын күргәндә – үгетнәсыйхәт бирү, белемебез белән кешеләргә хак вә хакыйкатьне аңлату, кешеләргә карата көләч йөзле, татлы телле булу һәм башка моңа охшаган эшләр кылу.

Бу икетөрле ярдәмнең дә савабы бардыр. Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дип боера:

**«Кем бер хәерле вә гүзәл эш эшләсә, ул кешегә ун кат савап булыр. Әгәр берәү начар эш эшләсә, аңа газап арттырылып бирелмәс, җәзасы эшләгән гөнаһы кадәр булыр».**

«Әнгам / Терлек», 6:160

Үзара ярдәмләшү вә юмартлыкның кыйммәтен арттырган нәрсә – кылган изгелекләребезнең Аллаһы белән безнең арабызда серле калуыдыр. Ярдәм вә ярдәмләшү белән мактану дөрес түгел, чөнки яхшылык эшләсәк тә, начарлык кылсак та – барлык эшләгән эшләребез Аллаһы Тәгалә өчен мәгълүмдер.

■ Сәхифә «Ислам дине нигезләре» китабыннан әзерләнде

# Курку хисе

Ислам динен үзе өчен хак дин дип тапкан һәр мөселман кешесе Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына омтыла. Вә һәрбер гамәлен дә, шуңа күрә, бүтән бертөрле дә ният белән башкармас. Әлбәттә, Кыямәт көнендә һәрбер кеше үзенең гәмәлләренең кем өчен башкарганын белер: Аллаһы ризалыгы өченме, йә булмаса, кеше күрсен дипме. Ә Кыямәт көнендә иң беренче соралачак нәрсә – намаз.

Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында бик күп мәртәбәләр мөэмин-мөселманнарга намаз укыгыз куша:

**«Намазларны үтәгез һәм зәкят садакасын бирегез һәм намаз укучылар белән бергә намаз укыгыз, ягъни Коръән юлында булган мөселманнардан аерылмагыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:43

Ягъни, намазларыгызны күңелегез вә тәнегез белән укыгыз, садакага лаек кешеләргә зәкят сәдакаларыгызны түләгез, рөкүгъка иелгәннәр белән беррәттән рөкүгъка иелегез. Намаз укучылар белән (рөкүгъка иелгәннәр) белән иелергә боеру – җәмәгать белән намаз укуны күз алдында тота.

Намаз укучылар өчен бер сыйфат турында әйтәсе килә, ул – хошугълыктыр, ягъни курку. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Тәхкыйк, хак мөэминнәр газаптан котылып, мәңгелек сәгадәткә ирештеләр. Алар намазларын хошугъ белән укыйлар, Аллаһыдан куркып, кечерәяләр».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:1-2

Аллаһы Тәгалә мөэминнәрнең бәхет-сәгадәткә ирешүләре турында әйтте һәм аның юлларын күрсәтте. Ягъни намазларыбызны курку вә басынкы халәтендә, буйсынып үтәү шулай ук намаз кабул булуның бер шарты булып тора икән. Хошугъ белән уку – үзеңне Аллаһы Тәгалә каршында басып торган кебек хис итү ул. Намаз укучының күңеле шушы хис аркасында тынычлана төшә, бертөрле килешкән хәлгә керә, намаздагы һәр хәрәкәте өчен борчыла. Ул намаз укыган вакытта чит гамәлләр эшләми, тирә-якка карамый, чөнки Аллаһы Тәгалә белән әңгәмә әдәбен сакларга тырыша.

■ Шамил Әхмәтгалиев

# Олы гөнаһлар

## Җитди сәбәпләрсез Рамазан аенда ураза тотмау

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аенда җитди сәбәпләрсез бер генә көн уразасын калдырган кеше, гомер буе ураза тотса да, бу уразасы кадәр әҗер ала алмаячак», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез шулай ук: «Ике намаз, ике җомга һәм ике Рамазан арасында зур гөнаһлардан ерак торган кешенең кечкенә гөнаһлары ярлыканыр», – дигән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ислам биш баганага нигезләнгән:

1. Иман китерү (шәһадәт);
2. Намаз уку;
3. Зәкят түләү;
4. Рамазан аенда ураза тоту;
5. Хаҗ».

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Исламның асылы һәм нигезе өч баганадан тора. Алар:

1. Аллаһы Тәгаләдән кала гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, дип шәһадәт китерү;
2. Намаз уку;
3. Зәкят түләү.

Боларның берсеннән генә булса да баш тарткан кеше имансыз була.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр дә кеше алдаудан, ялган белән эш итүдән, наданлыгыннан баш тартмый икән, Аллаһы Тәгаләгә андый кешенең су һәм ашаудан тыелып торуы (ач булуы) кирәкми».

Шулай ук ул: «Рамазан аенда ураза тотып та, гөнаһлары ярлыканмыйча калган кешегә хәсрәт булсын», – дип әйткән.

Рамазан аенда җидти сәбәпләрсез ураза тотмаган кеше, чит кешенең хакына керүче йә эчкечедән дә түбәнрәк икәнен барлык мөселманнар диярлек кабул итә.

Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын.

## Ятимнәр малын ашау

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Ятимнәрнең малларын золым белән (хаксызга) ашаган кешеләр карыннарын ут белән тутырачаклар һәм тиздән (мисалы булмаган бик куркыныч) ялкынга керәчәкләр».**

«Нисә / Хатыннар», 4:10

**«Балигъ яшенә җиткәнче, иң яхшы куллану (булган саклау һәм файда казандыру юллары) белән генә булмаса, ятим малына якын килмәгез; үлчәүне вә авырлыкны билгеләүне гаделлек белән (төптөгәл) башкарыгыз. (Үлчәүдә һәм чамалауда арттырмыйча яки киметмичә, төгәл гаделлек итү бик авыр булса да), Без һичкемгә көченнән килмәгәнне йөкләмибез. (Шул сәбәпле, сез, кулыгыздан килгәнчә, таләпчәнлек күрсәтсәгез, белми торып җибәрелгән ялгышларыгызны кичерербез). Сез (кешеләр хакында биреләсе хөкемнәр белән бәйле теләсә нинди мәсьәләдә) сүз әйткән чакта, (сүз әйтелгән кеше нәселлек ягыннан) якыныгыз (булып чыгарылачак хөкем аңа каршы) булса да, гадел булыгыз, (гадел булырга, әмер һәм тыюларын үтәү мәсьәләсендә) Аллаһыга биргән вәгъдәгезне тотыгыз. Ул (Аллаһы Тәгалә) боларны (үтәүне) сезгә әмер итте, – бәлки, (бу хөкемнәр турында яхшылап бер) уйларсыз (һәм кирәк булганча гамәл кылырсыз)».**

«Әнгәм / Терлек», 6:152

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам санап киткән җиде олы гөнаһ арасында ятимнәрнең малын ашау да бар.

Тәрбиягә алган кеше шул малдан аларга рөхсәт ителгән өлешне генә кулланырга ярый, аннан артыгын куллану – харам, бу кешегә хәләл ризык, хәләл мал булмаячак. Ул (хәләл) өлешне ислам дине кануннарына һәм горефләренә таянып хисаплап чыгарып була. Ул өлешне хисаплаганда начар ниятләр булырга тиеш түгел.

## Пәйгамбәребезгә яла ягу

*(ялган хәдисләр уйлап табу)*

Кайбер ислам галимнәре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата ялган сүзләр әйтү (Пәйгамбәребез әйтмәгән сүзләрне, аныкы дип белдерү) – кәферлек һәм исламнан чыгу була дип саный.

Дөреслектә, Аллаһы Тәгаләгә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә яла ягучы, хәләлне харам, харамны хәләл дип әйтүче кешеләр имансыз булалар. Галимнәрнең бүтән очракларга карата булган хөкемнәре бу хөкемнәрдән аерыла.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Миңа яла ягу (ялган хәдисләр уйлап чыгару, Пәйгамбәребез турында уйдырмалар чыгару) калган кешеләргә яла ягу белән тәңгәл түгел. Бу эшләрне аңлы рәвештә эшләүче кеше үзенә утта урын әзерләсен», – дип әйткән.

Шулай ук: «Мөселманда алдалау һәм хыянәттән кала, төрле сыйфатлар (мөселман төрле холыклы) була ала.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Минем исемнән ачык ялган сөйләүче кеше ике ялганчының берсе булып тора», – дип әйткән.

Бу хәдисләр ялган хәдисләрне уйлап чыгаруның тыелган эш икәнен күрсәтеп торалар.

## ЗИНА КЫЛУ

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

**«Зинага (керү түгел, кагылу һәм үбү кебек гөнаһларга хәтта) якынлашмагыз. Һичшиксез, ул бик җирәнгеч бер эш һәм (шәһвәтне канәгатьләндерү өчен эзләнә торган) бик кабахәт бер юл».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

**«Янә алар Аллаһы белән берлектә башка илаһка табынмыйлар (үтергән бер кеше өчен кыйсас, Исламга кергәннән соң диннән чыгу һәм өйләнгән килеш зина кылу кебек) хак белән булмыйча, Аллаһы тыйган җанны үтермиләр, зина да кылмыйлар. Кем дә кем боларны кылса, (гөнаһының) җәзасын алачак».**

«Фуркан / Аеручы», 25:68

**«Зина кылган хатын һәм зина кылган ир (балигъ яшенә җиткән, акыллы, мөселман һәм кол булмаган кешеләр икән, бигрәк тә бер тапкыр да кияүдә булмаган яки өйләнмәгән булсалар) – һәрберсенә йөзәр тапкыр (камчы белән) суктырыгыз. (Ләкин итләренә һәм сөякләренә зарар китерү максаты белән чамадан чыкмагыз, баш, йөз, корсак һәм җенси әгъзаларга сугудан да саклагыз.) Аллаһыга һәм Ахирәт көненә ышансагыз (беркемне дә кызганмагыз һәм сездән мәрхәмәтлерәк булган Яратучының хөкемен үтәр өчен), Аллаһының дине (гамәлгә ашырылу) мәсьәләсендә сезне кызгану (хисе) биләп алмасын. Мөэминнәрдән бер төркем ул икәүнең җәзасына шаһит булсын (шулай итеп, зина гөнаһының яманлыгы күрсәтелсен һәм бу җәза башкалар өчен гыйбрәт булсын)».**

«Нур», 24:2

**«Зина кылган ир зина кылган бер хатыннан яки ширек кушкан бер хатыннан башкага өйләнми. Зина кылган хатынны исә, аны зина кылган бер ир яки ширек кушкан бер ир генә хатынлыкка ала. Бу (зиначыларга өйләнергә яки кияүгә чыгарга) иман китерүчеләргә харам кылынды».**

«Нур», 24:3

Зинаның харамлыгы хакында фикер берлеге бар, ләкин зиначылар белән өйләнешү Исламның башыннан ук харам булса да, бераз соңрак, шушы ук сүрәнең, гыйффәтле гыйффәтсезгә бүлеп карамыйча, буйдакларны һәм толларны өйләндерергә әмер иткән 32 нче аяте кәримәсе белән нәсех ителгән. Фасикъларга охшау, гаептә шикләнү, начар сүзләргә мөмкинлек ачу кебек бик күп сәбәпләр аркасында гыйффәтсез хатыннарга өйләнү мәкруһ саналса да (Нәсәфи).

Берьюлы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән олы гөнаһлар турында сорадылар. Ул: «Сине барлыкка китергән Аллаһы Тәгаләгә ширек кылу, тукландыра алмаудан куркып үз балаңны үтерү, күршеңнең хатыны белән зина кылу», – дип җавап бирде.

Икенче бер хәдистә Расүлебез галәйһиссәламнең түбәндәге сүзләре риваять ителә:

«Мөэмин зина кылганда, урлаганда, хәмер эчкәндә имансыз халәттә була».

Тагын бер хәдистә: «Мөэмин кеше зина кылганда иманы чыгып, өстендә шәүлә кебек тора», – дип әйтелгән.

«Кеше күлмәген салган кебек, Аллаһы Тәгалә зина кылучының һәм исерткеч эчүченең иманын чыгара».

– «Аллаһы Тәгалә өч төркем кеше белән Кыямәт көнендә сөйләшмәс, аларга карамас һәм гөнаһларыннан чистартмас. Болар:

– зиначы карт ир кеше;
– ялганчы идарә итүче;
– тәкәббер ярлы кеше.

«Аллаһы Тәгаләнең дүрт төркем кешегә ачуы бар. Алар:

– күп вәгъдә бирүче сәүдәгәр;
– тәкәббер ярлы кеше;
– зиначы карт ир кеше;
– үзенең кул астындагыларга зыян салучы идарә итүче».

Иң авыр зина булып, кешенең үз әнисе, кыз туганы, әтисенең хатыны һәм аңа харам булган башка хатын-кызлар белән кылган зина санала.

■ **Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан тәрҗемә**

# Күңел күзе

(булган хәл)

Сәлимә әби җиденче язын күзләре күрмичә каршы ала. Бер күзе электән начар күрә иде аның, ә менә соңгы елларда икенче күзе дә күрми башлады. Табибларга да алып бардылар үзен. Элпә хасил булган, хирургия юлы белән ачып җибәргән очракта, бу күзең күрә башлаячак, апа, диделәр. Алай эшләттерәсе килмәде инде сигезенче дистәсен ваклаган Сәлимә әбинең. Ярый, хәерлеседер, тимик, балалар, диде. Менә сукыраеп, дөнья гүзәллеген күрә алмау бәхетеннән мәхрүм калуына җиде ел вакыт үткән. Тәрәзәдән кергән хуш исле шомырт исләре аның яраткан фасылы – яз килүен белдерә. Сәлимә әбине сукыр дип тә әйтеп булмый. Әнә, үзенең күңеленнән генә ул күз алдына ачык зәңгәр күк йөзен, анда эленгән куе ак болытларны, озын кышлардан соң яшеллеккә күмелә башлаган табигатьнең әкияти матурлыгын, яңа сулыш алып, «яшибез» дип белдергән урман-кырларны, болыннарны тасвирлый. Андый кеше сукыр була алмый. Күпме җаннар, боларны күреп тә, «күрмичә» гомер кичерә бирә. Каядыр чаба, ашыга, барысын да вакытка сылтап, дөнья куа. Сәлимә әби кебекләр андыйлардан түгел. Күзләре күрми башлауга һич кенә дә зарланмады ул. Мондый уйлар аның хәтта башына да килмәде. Күңеле чиста, саф булуының сәбәбе бу. Акъәби иде ул. Гомер буе биш вакыт намазын, уразасын калдырмаган, теленнән шөкер, хәмед-сәна сүзләре төшмәгән Сәлимә әби хәләле Дәүләтхан белән балалары булмауга да сабырлык күрсәтте. Раббым, димәк, язмагансың, нигъмәтләреңнең Хуҗасы Син генә, кемнәрне бүләкләүне дә бары Үзең хәл итәсең, диде ул. Ире, илебез өстенә кара болыт булып килгән ике сугышның да кичкән, тормыш күргән, авырлык аша үткән кеше иде. Бик матур яшәде алар. Бала-чагалары булмаса да, күпләрне сокландырып, берберләренә карата булган өлфәтмәхәббәт, хөрмәт-ихтирам хисләрен саклап, бер күз карашыннан аңлашып гомер кичерделәр. Менә хәләлен фани дөньядан озатканына да ун ел вакыт үткән. Сәлимә әби җиде ел инде олы җанлы, миһербанлы, һәркемгә ярдәмчел булган, җәйнең кызу көннәрендәге эш вакытларында да уразасын калдырмаган, һәр яңа туган көн өчен Раббысына рәхмәтле булып гомер итә белгән күршесе Гөлнисада яши. Аның ире дә яу кырында булып кайткан кеше иде. Аннан кайткач, озын гомер кичерә алмады, җанашым. Сигез баласын һәм хәләлен тол калдырып, бакыйлыкка күчте. Иң кечкенәләренә өч яше дә тулып җитмәгән иде. Менә шул тол хатын, күп балалы ана, тормыш йөген үз өстенә алып, уфтанмый, зарланмый, булганына шөкер әйтеп, эштән курыкмыйча, тормыш йөген тартып, балаларын аякка бастырды. Бүген исә, ул авыр көннәр артта калганда, газиз балаларының кадерле әнисе, оныкларының яраткан дәү әнисе булып яши.



Сәлимә әби уйларына бирелеп, баштан үткәннәрне кичереп утырганда, шау-гөр килеп өйгә Гөлнисаның балалары, оныклары килеп керде. Сәлимә әбинең урыны түрдә. Аның күз алдында үскән балалар, олылап, хөрмәтләп Сәлимә әби белән күрештеләр. Гөлнисаның балалары бик ярата иде аны, Сәлимә әбине үз әбиләре кебек күрделәр. Әбидән дини кыйссаларны, Расүлебез галәйһиссәламнең хәдисләрен тыңлап үстеләр. Сәлимә әби дин, әдәп-әхлак хакында, миһербанлы, ярдәмчел кешеләргә Раббысыннан нигъмәтләр биреләчәге турында яратып сөйли иде. Балалар боларның барысын да, ул вакытта күршеләре булган Сәлимә әбидән ишетеп үсте.

Бүген исә алар үзләре дә ата-ана. Хәзер аларның балалары Сәлимә әби янында бөтерелә. Сәлимә әби тәкъва, диндар булуына өстәп, шаян, зиһенле дә. Ул шул бәләкәчләргә кызык сөйләп, табышмаклар әйтеп, үзара ярыштырырга, шул рәвешле күңелләрен күрергә ярата. Оныклар аны яратып, Карт әби дип йөртәләр. Әбиләрен, килгән саен, әби сөйлә, әби уйнат, дип аптыраталар. Ә Сәлимә әбигә шул гына кирәк. Йөгез әле, кем әйтә ала, шул мәләдис, дип табышмаклар әйтә, кечерәкләренә бармак уены уйната.

Менә бүген дә әле өч яшьләре генә тулып киткән Алсу белән Гөлия, әби каршына йөгерешеп килделәр дә, мин беренче, юк, мин беренче дип, әбиләренең йомшак урыннарына сикерделәр. Бер-берсен уздырып, нидер сөйли, үзара бәхәсләшә башладылар. Әби мондый очракларда эче катып көлә. Бу гөнаһсыз сабыйларның әлеге халәтен маңгай күзләре белән күзәтә алмаса да, күңел күзе белән күреп, сөеп утыра ул аларны. Әби бәхәскә нокта куярга теләп, йөгез әле, кайсыгыз мине катырак сагынган икән, кем кысыбрак кочаклый дигән иде. Гөлиянең төрткечләүләренә ачуы килгән Алсу урыныннан сикереп төште дә, балаларча үпкәләп, борылып басты. Әниләре, балаларны дәү әниләренә калдырып, эшкә киткәннәр иде. Әллә шуңа да көе юк иде инде? Әбинең, кызым, кил инде, колагыңа бер сүз әйтәм, менә Гөлиягә әйттем инде, син белми калырсың алайса? дигән сүзләре Алсуга тагы да ныграк тәэсир итте, ахыры. Урамнан алып кергән кечкенә флагы белән әбигә кизәнеп җибәрде... Балаларча, уйнап кына кизәнү иде бу, сугам дип сукмады бала. Әмма таякчыкның очы әбинең күзенә тиеп китте. Сәлимә әбинең аһ, дип кычкырып җибәрүенә, аш бүлмәсеннән йөгереп кергән Гөлниса, баштa нәрсә булганын аңыша алмыйча, югалып калды. Каршында күзләрен тотып, башын иеп утырган әби һәм куркып калган кызчыклар... Кемгә карарга белмәгән Гөлия: «Без уйнадык кына, Алсу сукты», – дип елап җибәрде. Тормышының һәр мизгелендә сабыр булып кала алган Сәлимә әби, балаларны куркытмаска тырышты. «Хәзер, балалар, бераз авыртып кына китте, үтә ул, үтә», – диде. Тик, йә Раббым, нишләде минем күзем, дигән уй үтте башыннан. Ул бит берни дә күрмәсә дә, әле күз алмалары үз урынында иде. Моңа кадәр аның нурлы, ачык зәңгәр күзләре балкып торды. Ә хәзер ничек булыр? Сәлимә әби, балалар куркып, яныма килмәсәләр, нишләрмен, шулар белән юанып үзем дә балачагыма кайта идем, бит, дип уйлады. Аның уйларын Гөлнисаның каушап кына чыккан, Сәлимә апа, йә әле, ипләп кенә карап алыйм, дигән сүзләре бүлде.

Сәлимә әби әкрен генә кулларын алды... Саклык белән генә күз кабакларын күтәрде... Каршында үз сеңлесенә әйләнгән, ничәмә-ничә елларны якын күрешеләр булып яшәгән, бүгенге көндә иң кадерле кешесе булган Гөлнисаның нурлы йөзе. Еллар аның да маңгаенда үз эзләрен салган, күз кырыйларында каз тәпиләре ясап киткән сыман нәзек кенә җыерчыклар пәйда булган. Әмма, күңел гүзәллеге йөз-кыяфәтендә чагылыш тапкан бу кешене, еллар картайтмаган, ә, киресенчә, бизәгән генә. Агач җимеше белән, кеше эше белән, ди халык. Күп еллар баллы җимешләре белән кешеләрне куандырган агач, изгелекләре белән әйләнә-тирәгә нур чәчкән кешегә тиң.

Шулай итеп, әбинең күзләре күрә башлады. Күпмедер вакыт үткәч, бу хәлне көлеп искә алды олылар. Менә бит, Алсу, тагын ничә елларга күрү бәхетен бүләк иттең әбиеңә, табиб ярдәме дә кирәк булмады, диделәр. Ә Гөлниса апа белән Сәлимә әби моны бер могҗиза, Аллаһының рәхмәте итеп кабул итте. Күзләре күрә башлаганнан соң тагын ун ел яшәде Сәлимә әби. Гомеренең ун язын каршы алды, озатты. Кешегә бәхет өчен күп кирәкми. Шуларга куана белде ул. Әйе, күңел күзең күрмәсә, маңгай күзеңнең генә күрүе аз шул. Сәлимә әби, Гөлниса апа шикелле мөселмантатар хатын-кызлары бу дөньяны күңел күзләре белән күреп яши белделәр. Бу сәләткә бик бәхетлеләр генә ия була алды.

Сәлимә әби, йөз яшен тутырып, бакыйлыкка күчте. Аны кадерләп, хөрмәтләп соңгы юлга озаттылар. Гомеренең соңгы елларында аның янында күпме бала, онык, оныкчыклар җыелган иде. Шуларга куанып, бер-берләренең җылысын тоеп яшәделәр. Аларга Сәлимә әби, ә Сәлимә әбигә алар кадерле булды.

Кызык кеше язмышлары. Раббысы аңа нинди бүләк әзерләгәнен белми торып, алдан зарланмасын иде адәм баласы. Кодрәт иясе бирәүне дә үз рәхмәтеннән мәхрүм итми. Әмма, моны аңлар өчен, күңел күзләренә ия булу кирәк.

■ **Айсылу Юлдашева**

**ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ**

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| **7:50-8:05** | **Җиһанда Рамазан ае** |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Өйләгә азан |
| 12:10-12:20 | Җиһанда Рамазан ае |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 13:45-13:50 | Хәзрәткә сорау |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълиматы |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 16:50-17:05 | Җиһанда Рамазан ае |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| **17:30-19:00** | **Кәлам шәриф – мәгънәви тәрҗемә** |
| **19:08-20:03** | **Ахшамга азан, авыз ачу** |
| 20:10-20:25 | 40 хәдис |
| 20:30-20:33 | Миллият сүзлеге |
| 20:35-20:50 | Күңелдән күңелгә |
| 20:55-21:05 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 21:10-21:25 | Бәхет тулы йорт |
| 21:30-21:45 | 101 вәгазь |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

**ҖОМГА**

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Җомга тәбриге |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| **7:50-8:05** | **Җиһанда Рамазан ае** |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Җомга тәбриге |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:30-11:35 | Җомга тәбриге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Өйләгә азан |
| **12:10-12:20** | **Җиһанда Рамазан ае** |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 13:45-13:50 | Җомга тәбриге |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълиматы |
| 14:30-14:35 | Җомга тәбриге |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 16:50-17:05 | Җиһанда Рамазан ае |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| **17:30-19:00** | **Кәлам шәриф – мәгънәви тәрҗемә** |
| **19:08-20:03** | **Ахшамга азан, авыз ачу** |
| 20:10-20:25 | 40 хәдис |
| 20:30-20:33 | Миллият сүзлеге |
| 20:35-20:50 | Күңелдән күңелгә |
| 20:55-21:05 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 21:10-21:25 | Бәхет тулы йорт |
| 21:30-21:45 | 101 вәгазь |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

**ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ**

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 7:50-8:05 | Җиһанда Рамазан ае |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Өйләгә азан |
| **12:10-12:20** | **Җиһанда Рамазан ае** |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә р.г. |
| 13:45-13:50 | Хәзрәткә сорау |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълиматы |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Әд-дин вә әдәп |
| **16:50-17:05** | **Җиһанда Рамазан ае** |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| **17:30-19:00** | **Кәлам шәриф – мәгънәви тәрҗемә** |
| **19:08-20:03** | **Ахшамга азан, авыз ачу** |
| 20:10-20:25 | 40 хәдис |
| 20:30-20:33 | Миллият сүзлеге |
| 20:35-20:50 | Күңелдән күңелгә |
| 20:55-21:05 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 21:10-21:25 | Бәхет тулы йорт |
| 21:30-21:45 | 101 вәгазь |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә р.г. |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |




## ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты Рамазан ае уңаеннан “Рамазан. Ураза: еш бирелә торган сораулар” дигән китапчык бастырды

Без Рамазан аен ел саен зур кунакны көтеп алган кебек каршы алабыз. Уразаны да беренче ел гына тотмыйбыздыр. Әмма, кайсыбыз ураза һәм Рамазан ае турында барысын да беләм, дип әйтә ала? Әлеге хезмәттә уразага кагылышлы гомуми сораулардан башлап, тәравих намазы, аның зикерләренең гарәпчәсе, укылышы һәм мәгънәләре урын алган. Уразалы килеш сагыз чәйнәргә, спорт белән шөгыльләнергә, дару эчәргә ярыймы? Намаз укымаган кеше ураза тота аламы? Бу китапта әлеге һәм башка кызыклы сорауларга җавап таба алырсыз.

**Әлеге китапны «Хозур»ның huzurshop.ru сайты аша алырга мөмкин:**
Тел.: +7 (903) 305-45-43
Тел.: +7 (966) 250-00-09
**Интернет кибет:** huzurshop.ru/

## Изге Рамазан Шәриф ае дәвамында “Азан” радиосында татарча Коръән тәфсире хәтем кылыначак

Татарча Коръән тәфсирен “Азан” радиосында көн саен 17:30-19:00 сәгатьтә тыңлагыз. Радионың тапшырулар җәдвәлендә бу программа “Кәлам шәриф – мәгънәви тәрҗемә” атамасы белән килә. Исегезгә төшерәбез: Коръәни Кәримнең “Кәлам шәриф – мәгънәви тәрҗемә” дип аталган татарчага тәфсирен Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге эш төркеме башкарды. Китап шәкелендә Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәтенең “Хозур” китап нәшрият йорты бастырып чыгарды. Аудио вариантын ТР Мөселманнары Диния Нәзарәте “Хозур” оешмасының структур өлеше булган “Азан” дини радиосы эшләде. Татарча Коръән тәфсире танылган журналист, алып баручы Илдар Кыямов тавышы белән яздырылды.

### КАЗАН ӨЧЕН МАЙ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Сәхәр тәмам/ иртәнгә намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.05.2020 | 00:40 | 03:59 | 12:00 | 16:53 | 19:22 | 21:48 |
| 02.05.2020 | 00:31 | 03:57 | 12:00 | 16:54 | 19:24 | 21:52 |
| 03.05.2020 | 00:20 | 03:55 | 12:00 | 16:55 | 19:26 | 21:56 |
| 04.05.2020 | 00:06 | 03:53 | 12:00 | 16:56 | 19:28 | 20:58 |
| *Игътибарлы булыгыз! Намаз вакытлары үзгәрә* | | | | | | |
| 05.05.2020 | 01:51 | 03:51 | 12:00 | 16:57 | 19:30 | 21:00 |
| 06.05.2020 | 01:48 | 03:48 | 12:00 | 16:59 | 19:32 | 21:02 |
| 07.05.2020 | 01:46 | 03:46 | 12:00 | 17:00 | 19:34 | 21:04 |
| 08.05.2020 | 01:44 | 03:44 | 12:00 | 17:01 | 19:36 | 21:06 |
| 09.05.2020 | 01:42 | 03:42 | 12:00 | 17:02 | 19:38 | 21:08 |
| 10.05.2020 | 01:40 | 03:40 | 12:00 | 17:03 | 19:40 | 21:10 |
| 11.05.2020 | 01:38 | 03:38 | 12:00 | 17:04 | 19:42 | 21:12 |
| 12.05.2020 | 01:36 | 03:36 | 12:00 | 17:05 | 19:44 | 21:14 |
| 13.05.2020 | 01:34 | 03:34 | 12:00 | 17:06 | 19:46 | 21:16 |
| 14.05.2020 | 01:33 | 03:33 | 12:00 | 17:07 | 19:47 | 21:17 |
| 15.05.2020 | 01:31 | 03:31 | 12:00 | 17:09 | 19:49 | 21:19 |
| 16.05.2020 | 01:29 | 03:29 | 12:00 | 17:10 | 19:51 | 21:21 |
| 17.05.2020 | 01:27 | 03:27 | 12:00 | 17:11 | 19:53 | 21:23 |
| 18.05.2020 | 01:25 | 03:25 | 12:00 | 17:12 | 19:55 | 21:25 |
| 19.05.2020 | 01:24 | 03:24 | 12:00 | 17:13 | 19:56 | 21:26 |
| 20.05.2020 | 01:22 | 03:22 | 12:00 | 17:14 | 19:58 | 21:28 |
| 21.05.2020 | 01:21 | 03:21 | 12:00 | 17:15 | 20:00 | 21:30 |
| 22.05.2020 | 01:19 | 03:19 | 12:00 | 17:15 | 20:02 | 21:32 |
| 23.05.2020 | 01:17 | 03:17 | 12:00 | 17:16 | 20:03 | 21:33 |
| **Ураза гаете мөбарәк булсын!** | | | | | | |
| 24.05.2020 | 01:16 | 03:16 | 12:00 | 17:17 | 20:05 | 21:35 |
| 25.05.2020 | 01:15 | 03:15 | 12:00 | 17:18 | 20:06 | 21:36 |
| 26.05.2020 | 01:13 | 03:13 | 12:00 | 17:19 | 20:08 | 21:38 |
| 27.05.2020 | 01:12 | 03:12 | 12:00 | 17:20 | 20:10 | 21:40 |
| 28.05.2020 | 01:11 | 03:11 | 12:00 | 17:21 | 20:11 | 21:41 |
| 29.05.2020 | 01:09 | 03:09 | 12:00 | 17:22 | 20:12 | 21:42 |
| 30.05.2020 | 01:08 | 03:08 | 12:00 | 17:22 | 20:14 | 21:44 |
| 31.05.2020 | 01:07 | 03:07 | 12:00 | 17:23 | 20:15 | 21:45 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Апрель саны, №4 (297)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъват бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2748
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 28 нче апрельдә таратыла.
График буенча бу санга 27 нче апрель көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.